**Муниципальное автономное дошкольное образовательное учреждение «Детский сад №394 комбинированного вида с татарским языком воспитания и обучения» Советского района г. Казани**

**«КАБУЛ ИТЕЛДЕ»**
Педагогик киңәшмә утырышында
Бөркетмә № 1 от 29.08.2024г.

**«РАСЛЫЙМ»**
МАМБУ “394нче номерлы балалар бакчасы”.мөдире
_________________Ганиева Л.З.
Боерык № 34/ПД от 29.08.2024г

Ганиева Лейсан Закиржановна

Подписан: Ганиева Лейсан Закиржановна
DN: C=RU, S=Республика Татарстан (Татарстан), L=г.Казань, T=Заведующий, O="МУНИЦИПАЛЬНОЕ АВТОНОМНОЕ ДОШКОЛЬНОЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ ""ДЕТСКИЙ САД № 394 КОМБИНИРОВАННОГО ВИДА С ТАТАРСКИМ ЯЗЫКОМ ВОСПИТАНИЯ И ОБУЧЕНИЯ"" СОВЕТСКОГО РАЙОНА Г.КАЗАНИ", СНИЛС=05391318353, ИНН=166005257763, E=it-cbo@yandex.ru, G=Лейсан Закиржановна, SN=Ганиева, CN=Ганиева Лейсан Закиржановна
Основание: я подтверждаю этот документ своей удостоверяющей подписью
Местоположение: место подписания
Дата: 2024-08-29 11:34:00
Foxit Reader Версия: 9.7.2

# Татар теле тәрбиячеләренең эш программасы.
# Балалар бакчасында рус һәм башка милләт балаларына татар теле өйрәтү программасы
# 2024 –2025 уку елы

Эш программасын төзеделәр:
тэрбияче 1 кв.кат
Хусаинова Алфия Шамсевали кызы
тэрбияче 1 кв.кат
Муртазина Илсия Фәрит кызы

**КАЗАН, 2024ел**

**ЭЧТӘЛЕК**


| | | |
|---|---|---|
| | **КЕРЕШ СҮЗ** | 3 |
| **I** | **МАКСАТЛАР БҮЛЕГЕ** | |
| 1.1. | Аңлатма язуы | 3 |
| 1.1.1. | Программаның максаты һәм бурычлары | 5 |
| 1.1.2. | Программаны формалаштыруда принциплар | 6 |
| 1.1.3. | Балалар психик үсешенең яшь үзенчәлекләре | 7 |
| 1.2. | Программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре, максат ориентирлары | 12 |
| 1.3. | Программа буенча балаларның белем дәрәҗәләрен билгеләү | 16 |
| **II** | **ЭЧТӘЛЕКЛЕ БҮЛЕК** | |
| 2.1 | Балаларга үсеш юнәлешләре буенча белем бирү өлкәләре | 24 |
| 2.1.1. | Социаль – коммуникатив үсеш | 25 |
| 2.1.2. | Танып-белү үсеше | 26 |
| 2.1.3. | Сөйләм үсеше | 27 |
| 2.1.4. | Иҗади-сәнгать үсеше | 27 |
| 2.1.5. | Физик үсеш | 28 |
| 2.2 | Программаны тормышка ашыруда төрле технологияләр, формалар, чаралар | 28 |
| 2.2.1. | Тәрбияче белән балаларның бердәм эшчәнлеге | 31 |
| 2.2.2. | Педагоглар белән бердәм эшчәнлек | 31 |
| 2.2.3. | Балалар бакчасында тәрбияләнүче балаларның гаиләләре белән үзара бәйләнеш | 32 |
| **III** | **ОЕШТЫРУ БҮЛЕГЕ** | |
| 3.1. | Баланың үсешен тәэмин итү өчен психологик-педагогик шартлар тудыру | 33 |
| 3.2. | Үстерешле предметлы – тирәлек оештыру үзенчәлекләре | 33 |
| 3.3. | Программаны тормышка ашыруда кадрлар белән тәэмин итү | 34 |
| 3.4. | Материаль-техник тәэмин итү | 38 |
| 3.5. | Күңел ачу чаралары, бәйрәмнәр. | 38 |
| 3.6. | Норматив һәм норматив-методик документлар | 38 |
| 3.7. | Кулланылган әдәбият | 41 |
| | | |

# Кереш сүз

“Россия Федерациясендә белем турында” федераль закон - 29.12.2012 N 273-ФЗ (07.05.2013 үзгәртүләр кертелеп, 19.05.2013 гамәлгә кергән), “Татарстан Республикасы халыклары телләре турында” Татарстан Республикасы Законында һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасында мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәкле шартлар булдыру каралган. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән кабул ителгән 2010–2015 елларда мәгарифне үстерү стратегиясендә (30.12.2010, №1174) мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре өчен рус телле балаларны татарчага өйрәтү программасы, укыту-методик комплектлары (УМК) төзелде. Шулай ук ул 2010-2015 елларга мәгариф системасын үстерү стратегиясе кысаларында балалар бакчаларында балаларга туган тел өйрәтү, сөйләм үстерү юнәлешен тормышка ашыру максатыннан төзелгән һәм “Туган телдә сөйләшәбез” дип аталган методик әсбап балалар бакчасында беренче кече яшьтәге балалар белән эшләүче тәрбиячеләргә кулланма буларак тәкъдим ителде.

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар эмоциональ, хәрәкәтчән, тиз арыйлар. Бала материалны үзе өчен кызык булса гына, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килсә генә кабул итә һәм фикерли башлый. Телне өйрәтү процессында әкияти, фантастик сюжетлар, кызыклы геройлар белән очрашу, уен элементларын куллану – тел материалын өйрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә. Материалны кат-кат кабатлап, ятлап өйрәнүгә караганда, аралашу ситуацияләрендә сөйләм бурычына тәңгәл килгән лексик–грамматик материалны балаларның мөстәкыйль комбинацияләп сөйләшүе – тел өйрәнү өчен күп мәртәбә нәтиҗәлерәк алым. Димәк, эчтәлектә аралашу ситуацияләре һәм ситуатив күнегүләр системасы булу мәҗбүр. Телне аралашу ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә балалар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен шундук тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм тел өйрәнү процессының мотивлашкан булуын тәэмин ителә. Икенче телне өйрәнү вакытында бала, ихтыярсыз рәвештә, лингвистик материалны ана теле күренешләре белән чагыштыра. Бу – телне үзләштерү процессын җиңеләйтә. Димәк, һәр шөгыльгә программа материалын сайлаганда, балаларның ана теле буенча белемнәр системасын исәпкә алу зарур. Шөгыльләрдә ситуатив күнегүләрнең рус һәм татар телендә бирелүе балаларның белем сыйфатын күтәрүгә зур этәргеч булып тора. Баланың сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча түбәндәге белемнәргә ия булуы күздә тотыла: өйрәнелгән эчтәлек нигезендә әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белә; программадакүрсәтелгән темалар буенча тәрбиячененң сорауларына жавап бирә һәм сорау куя белә; бирелгән үрнәк диалоглар буенча охшаш диалоглар төзи, әңгәмәдә катнаша, терәк схемалар кулланып, ситуация буенча әңгәмә кора.

# I.Максатлар бүлеге

### 1.1. Аңлатма язуы

Балалар бакчасында татар теленә өйрәтү программасы (алга таба Программа) “Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасы структурасына Федераль дәүләт стандартларына (РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 23.11.2009 елда 655 нче карары нигезендә расланган) нигезләнеп төзелде. Программа 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле балаларның татарча аралашырга өйрәтү эшчәнлекләренең эчтәлеген чагылдыра. Программа тәлап иткән барлык метод һәм алымнар балаларны татар телен аралашу чарасы буларак кулланырга әзерләүгә юнәлдерелә.

“Татарстан Республикасы халыклары телләре турында” Татарстан Республикасы Законында һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасында мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәкле шартлар булдыру каралган. 2010-2015 елларга мәгариф системасын үстерү стратегиясендә балалар бакчаларында балаларга татар телен өйрәтү, сөйләм үстерү

юнәлешен тормышка ашыру максаты куелган. Мәктәпкәчә учреждениеләр, мәгариф системасының беренче баскычы буларак, нәниләрне татар теленә өйрәтүдә башлангыч роль уйный.

“Туган телдә сөйләшәбез” дип исемләнгән методик комплект беренче, икенче кече яшьтәгеләр, уртанчылар, зурлар, мәктәпкә хәзерлек төркемнәре өчен дә әзерләнә. Бу комплектның төп максаты балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү булса, төп үзенчәлеге – тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау (тоемлау) сәләте булдыру.

Туган телдә сөйләшергә өйрәтү гаиләдә башлана һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә дәвам итә. Ул балаларга ана телендә тәрбия һәм белем бирү өчен мөмкинлекләр тудыру, халкыбызның рухи байлыгына, мәдәниятенә якынайту шартларында алып барыла. Мәктәпкәчә учреждениеләр, мәгариф системасының беренче баскычы буларак, нәниләрне туган телгә өйрәтүдә башлангыч роль уйный.

Беренче кече яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеген оештыру системасы мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеген оештыру системасыннан аерыла. Балаларны туган телгә өйрәтү һәм сөйләм үстерү әйләнә-тирә белән таныштыру процессында бара. Шушы үзенчәлекләрне исәпкә алып, кече яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеге эчтәлеген төзегәндә әйләнә-тирә предметларны һәм күренешләрне танып белүдә нәрсә чыганак булып торуы игътибар үзәгенә алына.

“Татарча сөйләшәбез” дип аталган методик комплект балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләргә кулланма буларак тәкъдим ителә. Комплектка, балаларның яшь үзенчәлекләренә карап, методик кулланма, күрсәтмә һәм таратма әсбаплар, аудио һәм видеоматериаллар, балалар өчен эш дәфтәрләре туплап бирелгән. Методик комплектлар өч яшь төркеме (уртанчылар, зурлар, мәктәпкә әзерлек төркемнәре) өчен әзерләнгән, һәм аларның барысы да “Татарча сөйләшәбез” дип исемләнә. Бүгенге социолингвистик ситуациядә һәм гомуми белем бирүнең федераль дәүләт стандартлары тормышка ашу кысаларында рус телле балаларны татарча сөйләшергә өйрәтү буенча яңа укыту-методик кулланмалар эшләү зарурлыгы килеп басты.

Билгеле булганча, телгә өйрәтүнең максаты җәмгыять тарафыннан куелган социаль заказ белән билгеләнә. Татарстан Республикасының белем бирү системасына куйган төп бурычы – иҗади фикерләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле, ике дәүләт һәм чит телләрдә дә иркен сөйләшеп аралашучы шәхес тәрбияләү.

Рус телле балаларга татар теле өйрәтү максаты киңкырлы һәм ул берничә аспекттан тора: танып белү, үстерү, тәрбия, белем бирү.

Балаларның татар теле буенча лексик, грамматик күнекмәләре филологик белемнәр суммасы дәрәҗәсендә генә калмыйча, ә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә аралашуда кулланырлык дәрәҗәгә җитүе зарур. Ягъни, балалар, нинди дә булса сүзне, я грамматик категорияне тану, аеру, аңлау, тәрҗемә итү дәрәҗәсендә генә түгел, аларны аралашу максатында мөстәкыйль кулланырлык дәрәҗәдә өйрәнергә тиешләр. Шул вакытта гына татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү бурычы үтәлә.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга татар телен өйрәтү аларның билгеле бер күләмдә сүз байлыгын булдырудан, аралашудан башлана. Өйрәнелә торган материаллар – күрсәтмә әсбаплар, техник чаралар, мультфильмнар, тәрҗемә яки төрле хәрәкәтләр ярдәмендә аңлатыла. Пиктограммалар, терәк схемалар куллану уңышлы нәтиҗәләр бирә. Балалар тормышында уен зур урын тота. Шуна күрә программада балаларның татар теле дәресләрендә алган белем һәм күнекмәләрен ныгыту өчен күп төрле уеннар (сүзле, дидактик, сюжетлы, рольле, хәрәкәтле) тәкъдим ителә. Балаларның татар телендә сөйләшү күнекмәләре башка дәресләрдә дә, режим процессларында, экскурсияләр вакытында, бәйрәм иртәләрендә, спектакльләр караганда, музыка тынлаганда, төрле уеннар уйнаганда ныгыта барыла

### 1.1.1. Программаның максаты һәм бурычлары

Программаның максаты - татар телендә, шул исәптән башка милләт вәкилләре белән аралашу, халык уены, туган якны өйрәнү балаларны уңышлы социальләштерүне, мотивацияләүне һәм индивидуальләштерүне тәэмин итә торган милли мәдәният чаралары ярдәмендә рус телле баланың үсешен проектлау.

Матур әдәбият, халык иҗаты, күрсәтмәлелек, предметлар белән уен хәрәкәтләре, - болар барысы да балаларны туган телгә өйрәтүдә, аларның сөйләмен үстерүдә зур әһәмияткә ия. Шулай ук өйрәтү-тәрбия процессында балалар белән эшчәнлекне оештырганда тәрбиячегә иҗади якын килү мөмкинлеге дә бирелде. Балалар белән үткәрелә торган һәр эшчәнлеккә боларның барсын да истә тотып тулы, күләмле итеп план-конспектлар эшләнелде.

Шушындый укыту методик комплектлары, дидактик уеннар, яңа информацион технологияләр белән тулыландырылган тәрбия һәм белем бирү дәресләре балаларның телебезнең матурлыгын, байлыгын аңларга, аны сиземләргә, үзләрендә күркәм сыйфатлар булдырырга, тел хәзинәсен тирәнтен аңларга, кеше өчен газиз булган туган җиргә, туган телебезгә мәхәббәт, әти-әниләргә, өлкәннәргә карата хөрмәт-итәгать тәрбияләргә, үзләрендә хезмәт сөю, тыйнаклык, шәфкатьлелек кебек күркәм сыйфатлар булдырырга ярдәм итә.

Куелган максатка ирешү түбәндәге бурычларны хәл итү аша мөмкин:

- яшәү урынына, милләтенә, теленә, социаль статусына карамастан, мәктәпкәчә балачак чорында һәр баланың тулы канлы үсеше өчен тигез мөмкинлекләр тәэмин итү;
- шәхеснең гомуми культурасын формалаштыру, аларның социаль, әхлакый, эстетик, интеллектуаль, физик сыйфатларын, инициативалылыгын, мөстәкыйльлеген һәм җаваплылыгын үстерү, уку-укыту эшчәнлегенең алшартларын формалаштыру;
- туган якны өйрәнү өлкәсендә мәктәпкәчә һәм башлангыч гомуми белем бирү максатларының, бурычларының һәм эчтәлегенең дәвамчанлыгын тәэмин итү;
- татар телен үзләштерү һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләрен саклау, этникара мәдәниятне, һәр тәрбияләнүченең башка милләт вәкилләре белән үзара мөнәсәбәтләр субъекты буларак коммуникатив сәләтләрен үстерү өчен уңай шартлар тудыру;
- татар һәм рус халыкларының рухи-әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләре нигезендә укыту һәм тәрбияне берләштерү;
- төбәкнең милли үзенчәлекләрен исәпкә алып, балаларның яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләренә туры килә торган социаль-мәдәни мохит формалаштыру;
- гаиләгә психологик-педагогик ярдәм күрсәтүне тәэмин итү, гаилә тәрбиясе мәсьәләләрендә ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) компетентлыгын арттыру, белем бирү процессларының сыйфатын бәяләү.

Мәктәпкәчә яштәге балаларны татарчага өйрәтү уртанчылар төркемендә“Минем өем”, зурлар төркемендә “Уйный-уйный үсәбез”, мәктәпкә хәзерлек төркемендә “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проектына нигезләнеп алып барыла.

“Минем өем” проекты (4-5 яшь) өчен:

Максат: Татар теленә кызыксыну уяту, аралашу теләге тудыру.

Бурычлар:

1. Сүз байлыгы булдыру, сөйләмдә активлаштыру.
2. Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү.
3. Бер – береңне тыңлау, ишетү сыйфатлары тәрбияләү. “Уйный – уйный үсәбез” проекты (5-6 яшь) өчен:

Максат: Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта татарча аралашуга чыгу.

Бурычлар:

1. Сүз байлыгын арттыру, сөйләм күнекмәләре формалаштыру.
2. Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белү, көндәлек яшәештә аралашу.
3. Әдәпле итеп кара-каршы сөйләшә белү күнекмәләрен тәрбияләү. “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты (6-7 яшь):

Максат: Балаларның көнкүрешкә, табигатькә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.

Бурычлар:

1.Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү, файдалана белү күнекмәләренә өйрәтү.

2. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү, балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту.
3. Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен камилләштерү.
Моннан тыш, балаларны татар балалар әдәбияты һәм халык авыз иҗаты, татар халкының тарихы, гореф-гадәтләре белән таныштыру, мәдәнияты турында төшенчә бирү бурычы да куела.

### 1.1.2. Программаны формалаштыруда принциплар:

*Коммуникативлылык принцибы* –балаларны татар телен аралашу чарасы буларак куллануга әзерләүгә корылган. Телне фән буларак түгел, ә аралашу чарасы буларак өйрәтү.
*Интеграция һәм дифференциация принцибы* –һәр сөйләм төренең үз үзенчәлеген исәпкә алу, тәрбияче сөйләмен техник чаралар ярдәмендә (аудио-, видеоязмада) тыңлау (аудирование), тел үзәнчәлекләрен төрле күнегүләрдә бирү, балаларның диалогик сөйләмен үстерү;
*Күрсәтмәлелек принцибы* –тел өйрәтүне көндәлек тормыштагы һәр төрле эшчәнлеккә бәйле рәвештә, аларның тирә-юньне танып белүенең төп чарасы булып торган уен аша үткәрү;
*Тел өйрәтү, тәрбия һәм үстерү бурычларының бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тормышка ашыру принцибы;*
*Барлык белем бирү өлкәләрен берләштерү (интегральләштерү) принцибы:* социаль-коммуникатив, танып-белү, сөйләм үстерү, иҗади сәнгать, физик үсеш.
*Дәвамчанлык принцибы* –балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәптә эзлеклелекне күздә тоту;
*Белем бирүне комплекслы-тематик принципкакорып оештыру;*
*Белем бирү эшчәнлегенең мотивлашкан булу принцибы* -бала материалны үзе өчен кызык булганда, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килгәндә генә кабул итә һәм фикерли башлый. Телне өйрәтү процессында әкияти сюжетлар карау, кызыклы таныш геройлар (Акбай, Мияу) белән очрашу, уен элементларын куллану – тел материалын өйрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә. Телне аралашу, уен ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, балалар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм алар тел материалын бик теләп үзләштерәләр.
*Белем бирү эшчәнлегенең дидактик принцибы* -гадидән катлаулыга таба бару. *Индивидуальләштерү принцибы* - тел өйрәткәндә социаль шәхес сыйфатларын үстерүнекүздә тоту. Балаларның яшь үзәнчәлекләрен исәпкә алу.

### 1.1.3. Балалар психик үсешенең яшь үзенчәлекләре

**Беренче кечкенәләр төркеме (2 яшьтән 3 яшькә кадәр).** Өченче яшьтә балалар мөстәкыйльрәк була башлыйлар. Предметлы эшчәнлек, бала белән өлкәннәрнең ситуатив – эшлекле аралашулары усә бара, кабул итүчәнлекләрне, сөйләм, үз-үзләрен ирекле тотуның башлангыч формалары, уеннар, күрсәтмәле – тәэсирле фикер йөртүләре камилләшә.

Охшарга тырышу объекты сыйфатында һәм шулай ук балаларның үз активлыгын да үстерүче үрнәк итеп олылар тәкъдим иткән модель нигезендә, кораллы эш – гамәлләр табигый активлыгы, белем һәм күнекмәләр ярдәмендә барлыкка килүче активлыкка үзгәртеп, баланың ирекле тәртибен үстерәләр.

Олылар белән уртак предмет эшчәнлеге барышында сөйләмне аңлау үсә. Балалар үзләрен әйләндереп алган предмет исемнәрен үзләштерүен дәвам итәләр, олыларның гади сүз белән белдергән үтенечләрен үтәргә өйрәнәләр. Бала аңлый торган сүзләр саны шактый арта. Бала олыларның күрсәтмәләрен генә түгел, ә аларнң хикәяләүләрен дә аңлый башлый.

Балалрның актив сөйләме интенсив үсә. 3 яшькә алар төп грамматик структураларны үзләштерәләр, гади җөмләләр төзәргә тырышалар, өлкәннәр белән сөйләшкәндә барлык сүз төркемнәрен дә диярлек кулланалар. Актив сүзлек якынча 1000-1500 сүзгә җитә. 3 яшь туларак сөйләм баланың яшьтәләре белән аралашу чарасына әйләнә. Бу яшьтә балаларда уен, рәсем ясау, конструкцияләү кебек яңа өшчәнлек төрләре формалаша.

3 нче яшьтә күрү һәм ишетү сәләте камилләшә. Бу балаларга кайбер биремнәрне хатасыз үтәргә мөмкинлек бирә: 2 – 3 предметны формасы, зурлыгы һәм төсе буенча сайлап алу, көйләрне аеру, жырлау.

Бу яшьтәге балаларга уй – фикерләрне аңлап бетермичә әйтү, импульсивлык, хисләр һәм теләкләренең ситуцияләрдән бәйле булуы характерлы. Балалар яшьтәшләренеңэмоциональ халәтенә бик җиңел биреләләр. Шулай да бу чорда балада ирекле тәртип формалаша башлый. Ул кораллы эш – гамәлләр һәм сөйләм үсеше белән аңлатыла. Ба-лаларда горурлык һәм оялу хисләре барлыкка килә, исем һәм женси тәңгәллек белән бәйләнешле үзаң элементлары формалаша башлый. Иң кече яшьтәгеләр чоры 3 яшьлекләр кризисы белән тәмамлана. Бала үзенең олылардан аерылып торучы аерым кеше икәнлеген аңлый башлый. Анда Мин образы формалаша. Кризис күп кенә тискәре күренешләргә сәбәпче була: негативлык,кирелек,еш кына өлкәннәр белән мөнәсәбәт-ләрнең бозылуы п.б. Кризис берничә айдан 2 елга кадәр сузылырга мөмкин.

**Кечкенәләр төркеме (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)** 3–4яшендә бала әкренләп гаилә даирәсечикләреннән чыга. Аның аралашуы аерым хәлләргә генә бәйле булмый башлый. Өлкән кеше, бала өчен гаилә әгъзасы гына булып калмыйча, билгеле бер иҗтимагый функция йөртүчегә әверелә. Баланың шундый ук функция башкару теләге аны реаль мөмкинлекләре белән каршылыкка китерә. Бу каршылык мәктәпкәчә яшьтә эшчәнлекнең әйдәүче төренә әверелүче уен үсеше аша хәл ителә.

Шартлылык — уенның төп үзенчәлеге; бертөрле гамәлләрне бертөрле предметлар белән башкару аларны башка предметлар белән башкарылучы башка гамәлләргә кертүне күздә тота. Мәктәпкәчә яшьтәге кечкенәләр уенының төп эчтәлеге уенчыклар һәм алмаш уенчыклар белән эш итүдән гыйбарәт. Уенның дәвамлылыгы зур түгел. Мәктәпкәчә яшьтәге кечкенәләр бер-ике рольле һәм гади, җәенке булмаган сюжетлы уен белән чикләнәләр. Бу яшьтә кагыйдәле уеннар формалаша гына башлый. Баланың сурәтләү эшчәнлеге аның предмет турындагы күзаллауларына бәйле. Бу яшьтә әлеге
күзаллаулар формалаша гына башлыйлар. График образлар ярлы. Бериш балаларның рәсемнәрендә детальләр булмый, башкаларның рәсемнәре күбрәк детальләштерелгән булырга мөмкин. Балалар инде төс кулланырга мөмкин. Вак моторика үсеше өчен әвәләп ясау зур әһәмияткә ия. Мәктәпкәчә яшьтәге кечкенәләр өлкән кеше җитәкчелегендә гади предметларны әвәләп ясарга сәләтле. Аппликациянең аңга кабул итү үсешенә уңай йогынты ясавы мәгълүм. Бу яшьтә балалар аппликациянең гади төрләрен башкара алалар.

Мәктәпкәчә яшьтәге кечкенәләр конструкцияләү эшчәнлеге үрнәк буенча һәм уйланылганча катлаулы булмаган корылмалар төзү белән чикләнә. Бу яшьтә перцептив эшчәнлек үсеш кичерә. Балалар эталон алды берәмлекләрен (предэталон) — аңга кабул итүнең индивидуаль берәмлекләрен файдаланудан сиземләү эталоннарына — аңга кабул итүнең культура буларак үзләштерелгән чараларына күчәләр.

Мәктәпкәчә яшьтәге кечкенәләр төркеменнән күчү ахырына балалар 5 һәм күбрәк формадагы предметларны, 7 һәм күбрәк төсне кабул итәргә, предметларны зурлыклары буенча аерырга, балалар бакчасы төркемендә һәм, белем бирү процессын билгеле бер тәртиптә оештырганда, бөтен мәктәпкәчә учреждение бинасында да ориентлашырга сәләтле. Хәтер һәм игътибар үсеш кичерә. Өлкәннәр соравы буенча балалар 3–4 сүзне һәм предметларның 5–6 атамасын истә калдыра алалар. Мәктәпкәчә кечкенәләр яше ахырына алар яраткан әсәрләреннән зур өзекләрне истә калдырырга сәләтле. Күрсәтмә-гамәли фикерләү үсеше дәвам итә. Ситуацияләрне үзгәртү күп очракларда көтелгән нәтиҗәне исәпкә алып, максатчан сынаулар нигезендә гамәлгә ашырыла. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар предметлар арасындагы кайбер яшерен бәйләнешләрне һәм мөнәсәбәтләрне билгеләргә сәләтле.

Мәктәпкәчә яшьтәге кечкенәләрдә хыял үсеше башлана. Уенда, бер төрле объектлар башкаларын алыштырганда, хыял аеруча ачык чагыла. Балаларның үзара мөнәсәбәтләре нормалар һәм кагыйдәләр белән бәйле. Максатчан йогынты нәтиҗәсендә балалар чагыштырмача күп санда нормалар үзләштерә алалар, ул нормалар шәхси гамәлләрне һәм башка балаларның гамәлләрен бәяләү өчен нигез хасил итәләр. Балаларның үзара мөнәсәбәтләре уен эшчәнлегендә ачык чагыла. Актив рәвештә үзара багланышларга керүгә караганда, алар янәшә уйнауга ныграк тартылалар. Шулай да әлеге яшьтә үк үзара мөнәсәбәтләрне тотрыклы рәвештә сайлап кору күзәтелергә мөмкин. Балалар арасындагы низаглар башлыча уенчыклар аркасында килеп чыга. Баланың яшьтәшләре төркемендәге урыны күп очракта тәрбияче фикере белән билгеләнә. Мәктәпкәчә кечкенәләр яшендә

чагыштырмача гади ситуацияләрдә үзүзеңне тоту мотивларының бер үк вакытта бер үк нәрсәгә буйсындырылганлыгын күзәтергә мөмкин. Үз-үзеңне тоту белән аңлы рәвештә идарә итү әле формалаша гына башлый; күпчелек җәһәттә баланың үз-үзен тотышы ситуацияләргә бәйле. Шул ук вакытта баланың, телдән бирелгән күрсәтмәләргә кушылып, омтылышларын үзе үк чикләү очракларын күзәтергә мөмкин. Үз-үзеңне бәяләү үсеше башлана, бу очракта балалар күбесенчә тәрбияче бәяләмәсенә ориентлашалар. Шулай ук аларда җенси идентификация үсеше дәвам итә, бу исә сайлап алынган уенчыклар һәм сюжетлар асылында
чагылыш таба.

**Уртанчылар төркеме (4 яшьтән 5 яшькә кадәр)** Мәктәпкәчә урта яшьтәге балаларның уенэшчәнлегендә үзара рольләр багланышлары барлыкка килә. Бу исә мәктәпкәчә яшьтәге балаларның үзләрен кабул ителгән рольдән аера башлауларын күрсәтә. Уен барышында рольләр алмашынырга мөмкин. Уен гамәлләре балаларның үзләре өчен түгел, уен мәгънәсе өчен башкарыла башлый. Балаларның уендагы һәм чынбарлыктагы арадашлыгы бер-берсеннән аерыла. Сурәтләү эшчәнлеге шактый зур үсеш кичерә. Рәсем предметлы һәм детальләштерелгән төс ала. Кешенең график сурәте гәүдә, күзләр, авыз, борын, чәчләр, кайбер чакта кием һәм аның детальләре булуы белән сыйфатлана. Сурәтләү эшчәнлегенең техник ягы камилләшә. Балалар төп геометрик фигураларны ясый, кәгазьдән кайчы белән кисеп ала, сурәтләрне кәгазьгә ябыштыра алалар һ.б. Конструкцияләү эшчәнлеге катлаулана. Корылмалар 5–6 детальдән торырга мөмкин. Бала үзе уйлаганча конструкцияләү күнекмәләре, шулай ук гамәлләрнең эзлеклелеген планлаштыру формалаша. Баланың хәрәкәтләнү өлкәсе вак һәм эре моториканың позитив үзгәрешләре белән сыйфатлана. Җитезлек, хәрәкәтләр координациясе үсеш кичерә. Балалар бу яшьтә, үзләреннән
кечерәкләргә караганда, тигезлекне яхшырак саклыйлар, кечерәк киртәләр аша атлап чыгалар. Туплы уеннар катлаулана.

Мәктәпкәчә яшьтәгеләрнең уртанчы төркеменнән күчү ахырына балаларның аңга кабул итүе югарырак баскычка күтәрелә. Балалар теге яки бу предмет охшаган форманы атау сәләтенә ия булалар. Катлаулы объектларда гади формаларны аерып ала һәм гади формалардан катлаулы объектларны торгыза алалар. Балалар предметлар төркемнәрен сиземләнүче билге (зурлык, төс) буенча тәртипкә салырга; биеклек, озынлык һәм киңлек кебек параметрларны аерырга сәләтле. Тирәлектә ориентлашу камилләшә. Хәтер күләме үсә. Балалар 7–8 предметның атамасын истә калдыралар. Ирекле хәтер сәләте үсә башлый: балалар истә калдыру биремен кабул итәргә сәләтле, өлкәннәр кушкан йомышларны хәтерлиләр, зур булмаган шигырьләр ятлый алалар һ.б. Образлы фикерләү үсә башлый. Балалар, катлаулы булмаган мәсьәләләрне чишү өчен, схемалаштырылган гади сурәтләр кулланырга сәләтле.

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар схема буенча төзи, лабиринт мәсьәләләрне чишә алалар. Алдан күзаллау сәләте үсеш кичерә. Объектларның тирәлектә урнашулары буенча балалар аларның үзара тәэсир итешүе нәтиҗәсендә нәрсә булачагын әйтә алалар. Ләкин бу очракта аларга башка күзәтүче позициясенә басу һәм образны эчке планда үзгәртү кыен бирелә. Әлеге яшьтәге балалар өчен Ж. Пиаженың мәгълүм феноменнары (микъдар, күләм һәм зурлык саклану) хас. Мәсәлән, аларга кара төстәге өч кәгазь түгәрәк һәм ак төстәге җиде кәгазь түгәрәк тәкъдим итеп, «Нинди түгәрәкләр күбрәк — караларымы әллә акларымы?» дип сорасак, балаларның күпчелеге ак түгәрәкләрнең күбрәк булуын әйтер. Әгәр инде «Кайсы түгәрәкләр күбрәк — акларымы әллә кәгазьдән киселгәннәреме?» дигән сорау куйсак, җавап шундый ук булачак— аклары күбрәк. Хыял алга таба үсеш кичерә. Аның оригинальлек һәм иреклелек кебек үзенчәлекләре формалаша. Балалар бирелгән темага мөстәкыйль рәвештә әкият уйлап чыгара алалар. Игътибарның тотрыклылыгы арта. Бала 15–20 минут дәвамында тупланып эшли ала. Ул, ниндидер гамәлләр кылганда, хәтерендә катлаулы булмаган шартны саклап торырга сәләтле. Мәктәпкәчә урта яшьтә авазларны әйтү һәм дикция яхшыра. Сөйләм балалар активлыгы предметына әверелә. Балалар уңышлы рәвештә хайваннар тавышларын охшатып кабатлыйлар, интонация белән теге яки бу персонажларның сөйләмнәрен күрсәтә алалар. Сөйләмнең структурасы, рифмалар аларда кызыксыну уята. Сөйләмнең грамматик ягы үсеш кичерә.

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар грамматик кагыйдәләр нигезендә сүзләр иҗат итү белән шөгыльләнәләр. Балалар бер-берсе белән аралашканда, аларның сөйләменә ситуациягә

бәйлелек хас, өлкән кеше белән аралашканда, баланың сөйләме ситуациягә бәйсез рәвеш ала. Бала һәм өлкән кеше аралашуының эчтәлеге үзгәрә. Ул баланың конкрет халәте чикләреннән чыга. Танып белү әйдәүче мотивка әверелә. Бала аралашу процессында алган мәгълүмат катлаулы һәм аңлау өчен кыен булырга мөмкин, әмма ул аңарда кызыксыну уята. Балаларда өлкән кеше ягыннан ихтирам ителү ихтыяҗы формалаша, алар өчен аның мактавы аеруча мөһим булып чыга. Бу исә балаларның кисәтүләргә карата артык үпкәләүчәнлегенә китерә. Артык үпкәләүчәнлек яшь феномены булып тора. Яшьтәшләре белән үзара мөнәсәбәтләргә сайланганлык хас, бу бер баланы икенчесенә караганда якынрак итүдә күренә. Уеннар уйнаганда даими партнерлар барлыкка килә. Төркемнәрдә лидерлар аерылып чыга башлый. Көндәшлек, ярышучанлык барлыкка килә. Соңгысы үзеңне башкалар белән чагыштыру өчен мөһим, ул «Мин» образының үсешенә, аны детальләштерүгә китерә.
Яшьнең төп казанышлары уен эшчәнлеге үсеше белән, роль һәм чынбарлык арасында үзара бәйләнешләр барлыкка килү килү; сурәтләү эшчәнлеге үсеше; уйлаган буенча конструкцияләү, планлаштыру; аңга кабул итүне камилләштерү, образлы фикерләү һәм хыял үсеше, танып белү позициясенең эгоцентриклыгы; хәтер, игътибар, сөйләм, танып белү ихтыяҗы үсеше; өлкәннәр ягыннан ихтирамга ихтыяҗ формалашу, үпкәләүчәнлек, көндәшлек, яшьтәшләре белән ярышучанлык барлыкка килү; «Мин» образының алга таба үсеше, аны детальләштерү белән бәйләнгән. Зурлар төркеме (5 яшьтән 6 яшькә кадәр) Яшәешнең алтынчы елында балалар инде уен башланганчы ук рольләрне бүлә һәм рольгә карап үз-үзләрен тота беләләр. Уендагы үзара бәйләнешләр сөйләм белән бергә бара, эчтәлеге буенча да, интонация ягыннан да алынган рольгә туры килә. Балаларның реаль мөнәсәбәтләре вакытындагы
сөйләм рольдәге сөйләмнән аерылып тора. Балалар социаль мөнәсәбәтләрне үзләштерә һәм өлкәннәрнең төрле эшчәнлек төрләрендә позицияләр бәйлелеген аңлый башлыйлар, кайбер рольләр аларны башкаларына караганда ныграк җәлеп итә. Рольләрне бүлгәндә рольдә үз-үзеңне тоту тәртибе субординациясе белән бәйле низаглар да туарга мөмкин. Уен тирәлеген оештыру, анда мәгънәви «үзәк» һәм «периферия» аерылып чыгу күзәтелә. («Хастаханә» уенында андый үзәк — табиб кабинеты, «Чәчтарашханә» уенында — чәч кисү залы, ә көтеп утыру залы уен тирәлегенең периферияse сыйфатында күренә.) Балаларның уеннардагы гамәлләре төрлеләнә. Балаларның сурәтләү эшчәнлеге үсә. Бу иң актив рәсем ясау яше. Ел буена балалар ике меңгә якын рәсем ясарга сәләтле. Рәсемнәр эчтәлеге буенча төрледән төрле булырга мөмкин: бу балаларның тормыш тәэсирләре дә, хыялларындагы вакыйгалар да, фильмнарга һәм китапларга иллюстрацияләр дә. Гадәттә рәсемнәр төрле объектларның схематик сурәтләрен гәүдәләндерәләр, шулай да композиция чишелешенең оригинальлеге белән аерылып торырга, статик һәм динамик мөнәсәбәтләрне чагылдырырга мөмкин. Рәсемнәр сюжетлы төсмер ала; зур булмаган яки, киресенчә, зур үзгәрешләр булган күптапкырлар кабатланучы сюжетлар шактый еш очрый. Кешене сурәтләү детальләштерелгәнрәк һәм пропорциональрәк була бара. Рәсем буенча сурәтләнгән кешенең кайсы җенескә каравы һәм эмоциональ халәте турында хөкем йөртергә мөмкин. Конструкцияләү бу эшчәнлек барышындагы шартларны анализлый белү белән сыйфатлана. Балалар агач конструкторның төрле детальләрен файдаланалар һәм атыйлар. Төзү детальләрен кул астындагы материалга бәйле рәвештә алыштырырга мөмкиннәр. Үрнәкне өйрәнүнең гомумиләштерелгән ысулын үзләштерәләр. Балалар булачак корылманың төп өлешләрен аерырга сәләтле. Конструкцияләү эшчәнлеге схема нигезендә, уйлау һәм шартлар буенча тормышка ашырылырга мөмкин. Конструкцияләү уртак эшчәнлек барышында барлыкка килә. Балалар кәгазьдән, аны берничә мәртәбә бөкләп (ике, дүрт, алты бөгелеш); табигый материаллардан конструкцияләргә мөмкин. Алар конструкцияләүнең ике ысулын үзләштерә:
1) табигый материалдан — сәнгати образга (бала табигый материалны, аны төрле детальләр белән тулыландырып, бөтенлекле образ дәрәҗәсенә җиткереп «төзеп бетерә»);
2) сәнгати образдан — табигый материалга (бала образны гәүдәләндерү өчен кирәкле табигый материал сайлап ала). Т
өсне, форманы һәм зурлыкны; предметларның төзелешен аңга кабул итүнең камилләшүе дәвам итә; балаларның күзаллаулары системалаша. Алар төп төсләр һәм аларның төсмерләрен генә түгел, арадаш төс төсмерләрен; турыпочмаклыклар, оваллар, өчпочмакларның формаларын да атыйлар. Объектларның зурлыгын билгелиләр, төрле предметны артуга яки кимүгә таба бер рәткә җиңел тезәләр. Әмма балалар, формалары һәм тирәлектәге урыннары ярашмаган очракта,

объектларның тирәлектәге урынын анализлауда кыенлыклар кичерергә мөмкин. Бу ситуацияләрдә аңга кабул итүнең мәктәпкәчә яшьтәгеләр өчен, аеруча аларга бер үк вакытта берничә төрле һәм шуның белән бергә капма-каршы билгеләрне исәпкә алырга туры килсә, билгеле кыенлыклар тудыруы турында дәлилли. Мәктәпкәчә өлкән яшьтәгеләрдә образлы фикерләү үсеше дәвам итә. Балалар мәсьәләне күрсәтмә планда чишәргә генә түгел, объектны үзгәртеп коруны хәл итәргә, объектларның нинди эзлеклелектә үзара бәйләнешкә керүен күрсәтергә дә һ.б. сәләтле. Әмма моңа охшаш чишелешләр балалар адекват фикерләү чаралары кулланган очракта гына дөрес булып чыгачак. Алар арасында күрсәтмә модельләштерү процессында барлыкка килә торган схемалаштырылган күзаллауларны; объектларга хас билгеләр системасы турында күзаллауларны чагылдыручы комплекслы күзаллауларны, шулай ук төрле объект һәм күренешләрнең үзгәреш стадияләрен чагылдырган күзаллауларны (үзгәреш цикллары турында): ел фасыллары, көн һәм төн алмашу, төрлечә тәэсир итү нәтиҗәсендә объектларның зураюы һәм кечерәюе турында күзаллауларны, үсеш турында күзаллауларны һ.б. аерып күрсәтергә мөмкин. Моннан тыш, гомумиләштерүләр камилләшә бара, бу сүзле-логик фикерләүнең нигезе булып тора.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда әле объектларны төркемләү хакында күзаллаулар булмый. Балалар объектларны үзгәрергә мөмкин булган билгеләре буенча төркемлиләр, шул ук вакытта төркемнәрне логик кушу һәм күбәйтү операцияләре формалаша башлый. Мәсәлән, мәктәпкәчә өлкән яшьтәгеләр объектларны төркемләгәндә ике билгене: төсне һәм форма (материал) һ.б. исәпкә алырга мөмкиннәр. Илебез психологлары тикшеренүләре күрсәткәнчә, мәктәпкәчә өлкән яшьтәгеләр анализлана торган мөнәсәбәтләр аларның үз тәҗрибәсе чикләреннән чыкмаса, фикер йөртергә һәм дөрес аңлатмалар бирергә сәләтле. Хыял үсеше бу яшьтә балаларга шактый үзенчәлекле һәм үстерелешле вакыйгалар уйлап чыгарырга мөмкинлек бирә. Хыял бары аны активлаштыру буенча махсус эш алып барылган шартта гына актив үсеш алачак. Игътибарның тотрыклылыгы, аны бүлә һәм башка нәрсәгә күчерә белү үсә. Бәйсез игътибардан тиешле игътибарга күчү күзәтелә. Сөйләм, шул исәптән аваз юнәлеше, камилләшү дәвам итә. Балалар чыжылдаучы, сызгырулы һәм сонор тартыкларны дөрес әйтә алалар.

Фонематик ишетү, сюжетлы-рольле уеннар вакытында шигырь сөйләгәндә һәм көндәлек тормышта сөйләмнең интонацион тәэсирлелеге үсә бара. Сөйләмнең грамматик төзелеше камилләшә. Балалар гамәлдә барлык сүз төркемнәрен кулланалар, актив рәвештә сүзләр ясау белән шөгыльләнәләр. Лексика байый: синоним һәм антонимнар актив кулланыла. 246 Бәйләнешле сөйләм үсә. Балалар, картина буенча сөйләгәндә, төп вакыйга-предметларга гына түгел, детальләргә дә игътибар бирәләр. Әлеге яшь казанышларына уен эшчәнлегендә рольләрне бүлү; уен тирәлеген структуралаштыру; югары нәтиҗәлелек белән аерылып торучы сурәтләү эшчәнлегенең алга таба үсеше; конструкцияләүдә үрнәкне өйрәнүнең гомумиләштерү ысулын куллану; бер формадагы предметларны сурәтләүнең гомумиләштерелгән ысулларын үзләштерү хас. Бу яшьтә аңга кабул итү объектларның катлаулы формаларын анализлау белән билгеләнә; фикерләү үсеше фикерләү чараларын үзләштерү белән бергә бара (схемалаштырылган күзаллаулар, комплекслы күзаллаулар, үзгәрешләрнең цикллылыгы турында күзаллаулар); гомумиләштерү сәләте, сәбәпле фикерләү, хыял, бәйсез игътибар, сөйләм, «Мин» образы үсә бара.

**Мәктәпкә әзерлек төркеме (6 яшьтән 7 яшькә кадәр)**Сюжетлы-рольле уеннарда мәктәпкәәзерлек төркемендәге балалар кешеләр арасындагы характерлы тормышчан хәлләрне чагылдырган, мәсәлән, туй, бала туу, авыру, эшкә урнашу кебек катлаулы үзара бәйләнешләрне үзләштерә башлыйлар. Балаларның уен гамәлләре катлаулырак була бара, өлкән кешегә һәрвакытта да анык булмаган үзенә бер төрле мәгънә ала. Уен тирәлеге катлаулана. Бу тирәлектә һәрберсе үз сюжет сызыгын алып барган берничә үзәк булырга мөмкин. Шул ук вакытта балалар бөтен уен тирәлегендәге партнерларының үз-үзләрен тотышын күзәтергә һәм, шул үз урыннарына бәйле рәвештә, үзләре үк үз-үзләренең тотышын үзгәртергә сәләтле. Мәсәлән, бала инде сатучыга гади сатып алучы булып кына түгел, ә сатып алучы-әни яки сатып алучы-шофер буларак мөрәҗәгать итә. Рольнең башкарылуына рольнең үзе тарафыннан гына түгел, рольнең уен тирәлегенең кайсы өлешендә гәүдәләндерелүе белән дә басым ясала. Мәсәлән, автобус йөртүче ролен башкарганда, бала пассажирлар белән

җитәкчелек итә һәм ЮХИДИ инспекторына буйсына. Әгәр уен логикасы яңа рольнең барлыкка килүен таләп итсә, бала, элеккеге ролен саклап, уен барышында үзенә яңа роль алырга мөмкин. Балалар уенда теге яки бу катнашучыга рольнең башкарылуын шәрехли алалар. Сурәтләү эшчәнлегендә балалар тарафыннан чагылдырылучы әйләнәтирә тормыштан һәм әдәби әсәрләрдән китерелгән образлар катлаулана бара. Рәсемнәр тагын да детальләштерелгәнрәк рәвеш ала, аларның төсләр гаммасы баетыла. Малайлар һәм кызлар ясаган рәсемнәр арасындагы аерымлыклар ачыграк күренә. Малайлар бик теләп техниканы, космосны, сугыш хәрәкәтләрен һ.б. ны сурәтлиләр. Кызлар гадәттә хатын-кыз образларын — принцессаларны, балериналарны, модельләрне һ.б. ны рәсемгә төшерәләр. Көнкүреш сюжетлары да (әни һәм аның кызы, бүлмә һ.б.) еш очрый. Кешене сурәтләү детальләштерелгәнрәк һәм пропорциональрәк төс ала. Кулларда бармаклар, күзләр, авыз, борын, кашлар, ияк барлыкка килә. Кием төрле детальләр белән бизәлергә мөмкин. Дөрес педагогик караш булганда, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сурәтләү эшчәнлегендә иҗади-нәфис сәләтләр формалаша. Мәктәпкә әзерлек төркеменә кергәндә, балалар шактый дәрәҗәдә төзелеш материалыннан конструкцияләүне үзләштерәләр. Алар сурәтләрне һәм корылмаларны гомумиләштереп анализлау ысуллары белән иркен эш итәләр; төрле детальләрнең төп конструкция үзенчәлекләрен анализлау белән генә чикләнмичә, үзләренәтаныш күләмле предметлар белән охшашлык нигезендә детальләрнең формаларын билгелиләр. Ирекле корылмалар симметрияле һәм пропорциональ рәвешкә керә, аларны төзү күрү ориентациясе нигезендә башкарыла. Балалар кирәкле материалны тиз һәм дөрес сайлыйлар. Алар корылманың нинди эзлеклелектә төзеләчәген һәм төзү өчен кирәкле материалны җитәрлек дәрәҗәдә төгәл күзаллыйлар; үзләре уйлаганча һәм куелган шартлар буенча төрле катлаулылыктагы корылмалар төзи алалар. Бу яшьтә инде балалар кәгазь битен бөкләүләрнең катлаулы формаларын үзләштерәләр һәм үз формаларын уйлап чыгара алалар, ләкин аларны моңа махсус өйрәтергә кирәк. Эшчәнлекнең бу төре балалар өчен аңлаешлы гына түгел, ул аларның фәзаи (пространстволы) күзаллауларын тирәнәйтү өчен мөһим. Табигый материалдан конструкцияләү катлаулана. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар алдан ниятләп, катлаулы мөнәсәбәтләрне чагылдырырлык, кешеләр һәм хайваннар фигураларын үз эчләренә алган тулы композицияләр тудырырга сәләтле. Балаларда аңга кабул итү үсеше дәвам итә, ләкин алар берьюлы берничә төрле билгене һәрвакытта да исәпкә ала алмыйлар. Образлы фикерләү үсә, ләкин үлчәмнәрне чагылдыруда кыенлык кичерелә. Моны балаларга бер туры сызык өстендә урнашмаган тугыз нокта төшерелгән үрнәкне кәгазь битендә күчереп ясарга тәкъдим итеп җиңел тикшерергә мөмкин. Кагыйдә буларак, күчереп ясаганда, балалар нокталар арасындагы араларны дөрес билгеләмиләр: рәсемнәрне бер-берсе өстенә куйганда, бала рәсеменең нокталары үрнәктәге нокталар белән тәңгәлләшми. Гомумиләштерү һәм фикерләү күнекмәләре үсеше дәвам итә, әмма алар күбесенчә ситуациянең күренеп торган билгеләре белән чикләнә. Хыял сәләте үсеше дәвам итә, ләкин, зурлар төркеме белән чагыштырганда, бу яшьтә хыял үсешенең акрынаюы күзәтелә. Моны төрле йогынтылар, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларының балалардагы образларның стереотиплылыгына, үзгәрмәүчәнлегенә китерүче тәэсире белән аңлатырга мөмкин. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның игътибарлылык үсеше дәвам итә, игътибар ихтыяри төс ала.

Эшчәнлекнең кайбер төрләрендә ихтыяри туплану вакыты 30 минутка җитә. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда сөйләм, аның аваз ягы, грамматик төзелеше, лексика үсеше дәвам итә. Бәйләнешле сөйләм үсеш кичерә. Балаларның сөйләмнәрендә сүзлекнең баюы һәм шул яшьтә формалашучы гомумиләштерүләрнең үзенчәлеге чагыла. Балалар актив рәвештә гомумиләштерүче исемнәр, синонимнар, антонимнар, сыйфатлар һ.б. куллана башлыйлар. Дөрес оештырылган белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәсендә балаларда диалогик сөйләм һәм монологик сөйләмнең кайбер төрләре үсеш кичерә. Мәктәпкә әзерлек төркемендә мәктәпкәчә чор төгәлләнә. Аның төп казанышлары әйберләр дөньясын кеше мәдәнияте предметлары буларак үзләштерү; кешеләр белән позитив аралашу формаларын үзләштерү; җенси идентификация үсеше, мәктәп укучысы позициясе формалашу белән бәйле. Мәктәпкәчә чор ахырына бала танып белү һәм шәхес үсешенең югары дәрәҗәсенә ирешә, бу аңа киләчәктә мәктәптә уңышлы уку мөмкинлеге бирә.

**1.2. Программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре, максат ориентирлары** Уртанчылар төркеме балалары барлыгы якынча 62 сүз үзләштерә. Актив сүзләр: әти, әни, кыз, малай, мин, исәнмесез, сау булыгыз, исәнме, эт, песи, әйе, юк, сау бул, әби, бабай, әйбәт, ипи, алма, сөт, чәй, рәхмәт, мә, тәмле, кил монда, утыр, бир, аша, эч, туп, зур, кечкенә, матур, курчак, куян, аю, хәлләр ничек, уйна, пычрак, чиста, ю, бер, ике, өч, дүрт, биш (49 сүз). Пассив сүзләр: утырыгыз,бу кем?, кем юк?, син кем?, кем анда?, басыгыз, ал, ничә? нинди?(13 сүз).Уртанчылар төркемендә балалар үзлектән сорау куймыйлар, сорауларны тәрбияче бирә, бары. Хәлләр ничек? дигән сорауны гына бирәләр, ел ахырында алар бер-берсен сыйлый белергә тиешләр.

Зурлар төркеме балалары барлыгы якынча45 сүз үзләштерә, уртанчылар төркемендә өйрәнгән сүзләр ныгытыла. Актив сүзләр: кишер, нинди, баллы, ничә, суган, бәрәңге, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кыяр, кәбестә, кызыл, сары, яшел, кирәк, юа, нәрсә кирәк, аш, ботка, кашык, тәлинкә, чынаяк, зәңгәр, күлмәк, чалбар, ки, сал, йокла, бит, кул, өстәл, урындык, карават, яратам, бар (38 сүз). Пассив сүзләр: бу нәрсә?, хәерле көн, нәрсә бар? күп (7 сүз).

Барлыгы якынча 107 сүз.2 нче уку елы ахырына балалар түбәндәге белемнәрне үзләштерергәтиешләр:Бу кем? Бу нәрсә? Нинди? Ничә? сорауларына өстәп, Кем анда? Кем юк? Син кем?Нәрсә кирәк? Нәрсә бар? сорауларына аңлап җавап бирергә; раслаучы сүзләрне: әйе, бар,инкарь итүче: юк аңлап куллана белергә; тәрбияче кушкан боемнәрне аңлап үтәргә (мә, бир, ал, утыр, сана, аша, эч, сал, ки, йокла, җырла); матур итеп исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт әйтә белергә; балалар үзләре сорау куярга, гади диалогларда үзләрен ышанычлы сизеп сөйләшә белергә; төп хәрәкәтләрне белдерүче фигыльләрне аңлый һәм куллана белергә тиешләр (сикерә, уйный, җырлый, юа, ашый, эчә, ярата, кия, сала, утыра); әйберләрнең билгесен белдерә торган сүзләрне белергә: төсләр: кызыл, сары, яшел, зәңгәр; тәм: тәмле, баллы; зурлык: зур, кечкенә, күп, әз; билге: матур, чиста, пычрак, әйбәт; унга кадәр саный белергә; предметның урынын күрсәтергә: караватта, өстәлдә, урындыкта; грамматик конструкцияләр, гади җөмләләр төзергә; дүртьюллыкларны, җырларның сүзләрен яттан өйрәнергә, сәхнәләштерүдә катнашырга.

Мәктәпкә хәзерлек төркеме балалары ел дәвамында якынча 60 сүз үзләштерә. Шуның өстенә алар уртанчылар, зурлар төркемендә өйрәнгән сүзләргә таянып аралашалар (62+45 сүз). Мәктәпкә киткәндә балалар барлыгы якынча 167 сүз үзләштерергә тиеш.Актив сүзләр: син кем, хәерле көн, тычкан, бу кем? бу нәрсә? нишли?, йоклый, утыра, ашый, эчә, нишлисең?, ашыйм, эчәм, уйный, уйныйм, утырам, барам, кая барасың?, син нишлисең?,сикер, сикерәм, сикерә, йөгерә, төлке, йөгер, йөгерәм, чәк-чәк, өчпочмак, яшь, бүре, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, чана, шуа, шуам, бие, бии, биим, ак, кара, җырла, җырлыйм, зур рәхмәт, китап укый, рәсем ясыйм, укыйм, дәфтәр, нәрсә яратасың?(пассив сүз).

Мәктәпкә хәзерлек төркеме балалары Хәлләр ничек?Нинди? Ничә? Нәрсә кирәк? Син кем? Бу кем? Бу нәрсә?Нишли? Син нишлисең? Кая барасың? сорауларын бер-берсенә һәм зурларга бирә белергә һәм аларга җавап бирергә; “Кибет”, “Командир”, “Дусларны сыйлыйбыз”, “Телефоннан сөйләшәбез” кебек уеннарны мөстәкыйль рәвештә оештырырга һәм уйнарга, аралашырга тиеш.

**Уртанчылар төркеме(4-5 яшь).“Минем өем” проекты Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары**

1. Тирә- юнь күзаллавын киңәйтә барып, иң якын кешеләре, уенчыклар, ашамлыклархисабына сүз байлыгын арттыру.
2. Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган боемнәрне аңлап, үти белүләренә ирешү.
3. Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны кабатлап әйтә белүләренә ирешү.
4. Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт әйтә белү күнекмәләрен үстерү.
5. Куелган сорауларны аңлап, сөйләмдә 2-3 сүз белән җавап кайтару күнекмәләрен үстерү.

**Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге**

**Лексик минимум** –якынча 62 сүз.

“Минем өем” проекты темалары (“Гаилә”,“Ашамлыклар”,“Уенчыклар”,“Саннар”) буенча бирелгән лексиканы төрле ситуацияләрдә ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.

Аларның тирә-юнь күзаллавын киңәйтә бару, югарыда күрсәтелгән темага караган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын арттыру өстендә эшләү, аларда татар телендә сөйләшә башлау теләге уяту.

Актив үзләштерүләренә ирешү өчен әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлату һәм аларны дөрес әйтү күнегүләре эшләү. Иң якын кешеләр (*әти,әни,бабай,әби,малай,кыз)*, яраткан уенчыклар (*туп,машина,курчак,эт,песи куян,аю),* ашамлыклар *(алма,ипи,сөт,чәй)* һәмсаннар *(бер,ике,өч,дүрт,биш)* хисабына сүзлекне баету һәм активлаштыру. Өйрәнгән сүзләрне аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белү күнекмәләрен булдыру. *Алма бир.Мә, алма*.
Бу кем? Бу нәрсә? сорауларын аңлап җавап бирергә өйрәтү.
*-Бу кем? – Бу әти.*
*-Бу нәрсә? – Бу туп.*
Нинди? соравын аңларга, дөрес җавап бирергә өйрәтү.
*-Туп нинди? – Кечкенә.*
*-Машина нинди? – Матур.*
Әйбернең билгесен ачыклау максаты белән куела торган сорауларны аңларга һәм сөйләмдә җавап кайтарырга өйрәтү. (Зур, матур, кечкенә, чиста, әйбәт, пычрак, тәмле).
*-Бу нәрсә? – Бу туп.*
*-Туп нинди? – Туп пычрак (зур, матур, кечкенә, чиста, әйбәт).*
Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны балаларның кабатлап әйтә белүләренә ирешү өстендә эшләү. Аларның өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган боемнәрне аңлап, үти белүләренә ирешү *(мә,бир,утыр,аша,эч,уйна,ю,ал).*
*-Мә, куян. – Бир куян.*
Тәрбияче әйткән билге буенча предметны табу, күрсәтә белергә өйрәтү.
*Зур машина ал. Тәмле алма бир.*
Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша белергә өйрәтү, сүзләрне дөрес, урынлы куллану.
*Исәнме. – Исәнмесез. Сау бул. – Сау булыгыз. Мин кыз. - Мин Оля. Мин малай - Мин Коля.*
Таныш предметларның исемнәрен ныгыту, куелган сорауга раслаучы, инкарь итүче сүзләрне *(әйе, юк)* дөрес кулланырга өйрәтү
*Син Коля? – Әйе.*
*Син кыз? – Юк, мин малай.*
Мин, син алмашлыкларын аңларга һәм урынлы кулланырга өйрәтү.
*Син кем? – Мин Коля.*
Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар өйрәтү.

**Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре:**
Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган боемнәрне аңлап, үти белә.
Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны кабатлап әйтә белә.
Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт әйтә белә.
Куелган сорауларны аңлап, сөйләмдә 2-3 сүз белән җавап кайтара белә.
Бер-берсе һәм өлкәннәр белән якынча 62 сүз кулланып татар телендә аралаша.
Бирелгән лексиканы төрле ситуацияләрдә ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.
Татар телендә сөйләшү теләге бар.
Әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлый һәм аларны дөрес әйтә белә.
Гаилә, уенчыклар, ашамлыкларһәм саннар хисабына сүз байлыгы бар.
Өйрәнгән сүзләрне аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белә.
Бу кем? Бу нәрсә? сорауларын аңлап, җавап бирә.
Әйбернең билгесен ачыклау максаты белән куела торган сорауны аңлый һәм сөйләмдә җавап кайтара белә.
Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны кабатлап әйтә. Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган боемнәрне аңлап үти.
Тәрбияче әйткән билге буенча предметны таба, күрсәтә белә.
Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша белә, сүзләрне дөрес, урынлы куллана.
Куелган сорауга раслаучы, инкарь итүче сүзләрне дөрес кулланана белә.
Мин, син алмашлыкларын аңлый һәм урынлы куллана.
Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар белә.

**Тәрбияче һәм ата- аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:**
Сүз байлыгын арттыру. Бирелгән лексиканы ишетеп аңлый, куллана белү. Сорауларны аңлый, җавап бирү. Мин, син алмашлыкларын урынлы куллана белү.

**Зурлар төркеме (5-6 яшь).“Уйный – уйный үсәбез” проекты Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары**

1. Тирә- юнь күзаллавын киңәйтә барып, яшелчәләр, савыт-сабалар, киемнәр, өй җиһазлары, ашамлыклар темасына кергән сүзләр хисабына сүз байлыгын арттыру.
2. Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белүләренә ирешү.
3.Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта татарча аралашуга чыгуларына ирешү.
4.Сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү.
5.Боерык фигыльләрне сөйләмдә аңлап дөрес куллана белү күнекмәләрен үстерү.

**Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге**
**Лексик минимум** –якынча45сүз.
“Уйный-уйный үсәбез” проекты темалары (“Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар”, **“**Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.
Яңа сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру. (*Кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, аш, ботка, кашык, тәлинкә, чынаяк, күлмәк, чалбар, бит, кул, өстәл урындык, карават, баллы, ничә, нинди, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кызыл, сары, яшел, зәңгәр, нәрсә кирәк, юа, ки, сал, йокла, хәерле көн, яратам, бар).*
Санау күнекмәләрен ныгыту, сөйләмдә камилләштерү.
Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә өйрәтү.
Раслаучы һәм инкарь итүче сүзләрне ныгыту, урынлы куллану. *(Әйе, юк)* Исем + сыйфат конструкциясен сөйләмдә активлаштыру.
*- Бу кызыл тәлинкә.*
“Минем өем” проекты буенча өйрәнелгән боерык фигыльләрне ныгыту *(аша, эч, утыр, ю, уйна, йокла)*, яңа боерык фигыльләрне *(ки, сал)* сөйләмдә аңлап дөрес куллана белергәөйрәтү, активлаштыру.
Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү.
**Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре**
Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белә.
Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта107 сүз кулланып татар телендә аралаша. Сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә
куллана.
Боерык фигыльләрне сөйләмдә аңлап, дөрес куллана.
“Уйный-уйный үсәбез” проекты темалары (“Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар”**,** **“**Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.
Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы бар.
Санау күнекмәләре бар, сөйләмдә куллана белә.
Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә.
Раслаучы һәм инкарь итүче сүзләрне аңлый, урынлы куллана.
Исем + сыйфат конструкциясен сөйләмдә дөрес куллана.
Боерык фигыльләрнесөйләмдә аңлап дөрес куллана белә.
Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана белә.
**Тәрбияче һәм ата- аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:**

Сүз байлыгы арттыру. Бирелгән лексиканы ишетеп аңлый, куллана белү. Сорауларны аңлый, мөстәкыйль рәвештә сорау куя белү. Сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана алу.

**Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь)**.“**Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты**

**Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары**

1. Ашамлыклар, кыргый хайваннар, кошлар, мәктәп темасына кергән сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру.
2. Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү, файдалана белүкүнекмәләренә өйрәтү.
3. Диалогик һәм монологик сөйләмне үстерү.
4. Мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә күнектерү.

**Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге Лексик минимум** –якынча60сүз.

“Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты темалары ( “Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” **, “**Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”, “Танышу”, “Тату гаилә”, “Дусларны сыйлыйбыз”, “Кунак килде”, “Кафега барабыз”, “Күңелле уеннар”, “Без циркта”, “Безнең дуслар”, “Чана шуабыз”, “Без биибез”, “Күңелле сәяхәт”, “Мәктәп”, “Без әкият ятатабыз”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (танып – белү, уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.

Яңа сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру: *син кем, хәерле көн, тычкан, бу кем, бу нәрсә, нишли, йоклый, утыра, ашый, эчә, нишлисең, ашыйм, эчәм, уйный, уйныйм, утырам, барам, кая барасың, син нишлисең, сикер-сикерәм, сикерә, йөгерә, төлке, йөгер-йөгерәм, чәк-чәк, өчпочмак, яшь, бүре, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, чана, шуа, шуам, бие, бии, биим, ак, кара, җырла-җырлыйм, зур рәхмәт, китап укый, рәсем ясыйм, укыйм, дәфтәр.*

Бу кем? Бу нәрсә? Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Нишли? Син нишлисең? Кая барасың? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә өйрәтү.

Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү. Монологик сөйләмне үстерү.

**Белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләре:**

Сөйләмне аралашу чарасы буларак файдалана белә. Диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләре бар. Мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белә.

Бер-берсе һәм өлкәннәр белән 167 сүз кулланып татар телендә актив аралаша.

“Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты темалары ( “Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” **, “**Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”, “Танышу”, “Тату гаилә”, “Дусларны сыйлыйбыз”, “Кунак килде”, “Кафега барабыз”, “Күңелле уеннар”, “Без циркта”, “Безнең дуслар”, “Чана шуабыз”, “Без биибез”, “Күңелле сәяхәт”, “Мәктәп”, “Без әкият ятатабыз”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (танып – белү, уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләрен бар.

Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы бар.

Бу кем? Бу нәрсә? Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Нишли? Син нишлисең? Кая барасың? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белә.

Фигыльләрне урынлы куллана. Җырлар, шигырьләр белә.

**Тәрбияче һәм ата- аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:**

Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы арттыру. Бирелгән лексиканы диалогик һәм монологик сөйләмдә куллана алу.

“Бу кем?”, “Бу нәрсә?”, “Нәрсә кирәк?”, “Нинди?”, “Ничә?”, “Нишли?”, “Син нишлисең?” “Кая барасың?” сорауларын мөстәкыйль рәвештә куя белү. Фигыльләрне урынлы куллану.

**1.3. Программа буенча балаларның белем дәрәҗәләрен билгеләү**

Балаларның татар телендә аңлау һәм сөйләшә (аралаша) белү күнекмәләрен уку елы башында (октябрь ае) һәм уку елы ахырында (апрель аенда) тикшерелә. Уртанчылар төркеме

балалары белән тикшерү уку елы ахырында үткәрелә. Уку елы уртасында тематик тикшерү (декабрь, январь) үткәререгә мөмкин.
Тикшерүне һәр бала белән аерым, 1 – 2 бала катнашында, ә йомгаклау эшчәнлеге булганда барлык балалар белән бергә дә үткәрергә була. Тикшерү вакыты 10-15 минутан артмаска тиеш.

Биремнәр балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып үткәрелә, уен-бирем рус телендә аңлатыла. Биремнәр мавыктыргыч һәм кызыклы булырга тиеш. Сораулар ачык, төгәл итеп, интонация белән бирелә.Тикшерүче балаларның җавабын тыңлаганда елмаеп, кирәк булса җавапны дөресләп, бала әйтә алмаганда булышырга тиеш.

Тикшерү барышында яңа материал бирелми. Тикшерүне эш дәфтәрләре, таратма, күрсәтмә рәсемнәр, интерактив тактада уеннар кулланып үткәрергә дә була.

Биремнәр, уеннар өчен кирәк булган күрсәтмәлелек алдан әзерләнеп куелган булырга тиеш. Тикшерүче һәр биремгә аерым балл куеп бара. Тикшерү ахырында баллар саны кушыла һәм 5 кә бүленә. Шулай итеп гомуми нәтиҗә ясала.

**Уку елы ахырында уртанчылар, уку елы башында зурлар төркеме балаларының “Минем өем” проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.**

**1. “Минем өем”проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану.**

1. ***Дидактик уен. "Бу кем?"****(Івариант)*

Лексика: әти, әни, кыз, малай, әби, бабай)
Уен эчтәлеге: Өй рәсеме. Өй тирәсендә гаилә әгъзалары рәсемнәре (комплекттагы күрсәтмә рәсемнәр). Тәрбияче рәсемнәргә күрсәтеп сорый: Бу кем? ("Әни"...).

2. ***Дидиктик уен "Кем юк?"*** *(ІІвариант)*

(Лексика шул ук). Уен шул ук рәсемнәр кулланып үткәрелә. Тәрбияче бер рәсемне алып куя. Баладан сорый: "Кем юк?" ("Әби"...)
Уенны интерактив тактада да, бала белән бала арасында диалог формасында да үткәрергә була)

3. ***Дидактик уен "Кәрзиндә нәрсә бар?"*** (Лексика: ипи, алма, сөт, чәй)

Уен эчтәлеге: Мияу кәрзин белән ашамлыклар алып килгән. Мияу ашамлык муляжларынакүрсәтә, исемен сорый: "Бу нәрсә?" ("Алма"...)

4. ***Дидактик уен "Нәрсә юк?"***

Мияу бер ашамлык муляжын яшереп куя: "Нәрсә юк?". Бала нәрсә юклыгын әйтергә тиеш. ("Алма"...) Уенны рәсемнәр кулланып та үткәреп була.

5. ***Дидактик уен "Мин әйтәм, син күрсәт һәм әйт"***

(Лексика: әти, әни, кыз, малай, әби, бабай; куян, аю, туп, машина, курчак, эт, песи, ипи, алма, сөт, чәй).
Уен эчтәлеге: Балага уенчык яисә уенчык рәсемнәре бирелә. Бала, тәрбияче әйткәнуенчыкны яисә уенчык рәсемен табып күсәтергә һәм исемен кабатлап әйтергә тиеш.

6. ***Дидактик уен "Исемен әйтсәң бирәм"*** (Лексика: куян, аю, туп, машина, курчак, эт, песи)

Уенэчтәлеге: Тәрбияче өстәленд әуенчыклар яисә рәсемнәр. Тәрбияче балагауенчыкны(рәсемне) күрсәтә, сорый: "Бу нәрсә?"- "Алма"…; "Бу кем?"-"Әти"...Бала уенчык исемен дөрес әйтсә аңа уенчыклар, яисә таратма рәсемнәр бирелә.

7. ***Дидактик уен "Серле янчык"***

(Лексика: куян, аю, туп, машина, курчак, эт, песи)
Уен эчтәлеге: Балага уенчыклар күрсәтелә, исемнәрен әйтеп янчыкка салына. Бала янчыктагыуенчыкны капшап исемен әйтә, алып күрсәтә.

8. ***Дидактик уен "Әйе-юк"***

Сүзнең дөрес үзләштерелүен тикшерү йөзеннән (аңлап яки аңламыйча әйтү) төрле вариантта сораулар бирелә: "Бу нәрсә?" - "Аю"...; "Бу аю?" -"Әйе, аю"...; "Бу куян?" - "Юк, песи"...

**Югары балл(2.7-3)**—сүз байлыгы җитәрлек,уенчык,әйберләрне үзлектән,аңлап дөрескүрсәтә, исемнәрен әйтә.
**Уртача балл(2-2,6)**-сүз байлыгы бар,кайбер сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.
**Уртачадан түбән балл(1-2)**-аңлый,русча җавап бирә.

**2. Ягымлы сүзләр куллану ("исәнме", "сау бул", "рәхмәт").**

***Ситуатив күнегүләр:***
а) Ситуатив күнегү "Куян аюга кунакка килә". Ул ишектән кергәндә аюга нәрсә әйтә? (Ничек исәнләшә?), "Исәнме аю".
б) Ситуатив күнегү "Куян аюда кунакта булды". Ишектән чыгып киткәндә куян аю белән ничек саубуллаша? (Нәрсә әйтә?) "Сау бул, аю".
в) Уен ситуациясе "Кунак сыйлау". Акбайда (Мияуда) кунакта.
Тәрбияче Акбай (Мияу) ролендә. Ул баланы, ашамлык, җиләк-җимеш (алма, груша, банан һ.б.) муляжлары белән "сыйлый". Тәрбияче баланың "рәхмәт" әйтә белүен билгели.
г) Уен ситуациясе "Дустыңны сыйла". Балаларны парлаштырып бер-берсен сыйларга тәкъдим итү. Рәхмәт әйтә белүләрен билгеләү.
д) Ситуатив күнегү "Акбайга ("Мияуга", "Курчакка", "Дустына") уенчык бүләк ит". **Югары балл (2,7-3)**-бала ситуацияләрдә ягымлы сүзләрне урынлы куллана. **Уртача балл (2-2.6)**-тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.
**Уртачадан түбән (1-2)**- аңлый, сорауга җавапны русча әйтә.

**3. Боерыкны аңлап үтәү һәм куллана белү (кил, утыр, сикер, ю, аша, эч).**
**1. Сүзле уен "Мин әйтәм - син эшлә" ("Командир").**
**2. Сүзле уен "Шаян уенчыклар"** (Уен баланың боерыкларны аңлы рәвештә үтәвен тикшерүөчен бирелә. Уенның эчтәлеге: Тәрбияче уенчыкка боерык бирә, мәсәлән: Утыр! Ә уенчык "ашый" башлый. Бала боерыкны дөрес итеп үтәп күрсәтә).
**Югары дәрәҗә (2,7-3)**-бала боерыкны аңлап, дөрес үти.
**Уртача дәрәҗә (2-2,6)** -ялгыша.
**Уртачадан түбән дәрәҗә (1-2)**-татарча аңламый, боерыкларны үтәми.

**4.Тирә-юньдәге предметларның сыйфат билгеләрен, күләмен белдерә торган сүзләрне аңлап сөйләмдә куллану.**

1. ***Дидактик уен "Уенчык нинди?" (зур, кечкенә, чиста, пычрак, әйбәт, матур).***

Уен эчтәлеге: зур-кечкенә уенчыклар күрсәтелә. Тәрбияченең "Нинди?" соравына бала уенчыкның исемен сыйфат билгесе белән әйтергә тиеш.
-Нинди курчак? - Зур (кечкенә, чиста, пычрак, әйбәт, матур) курчак.
Эш дәфтәрендәге 11 нче биремне кулланып була.

2. ***Дидактик уен"Тап, күрсәт һәм әйт" (чиста, пычрак).***

Комплекттагы күрсәтмә рәсемнәр кулланып үткәрелә. Тәрбияче әйткән рәсемне бала табып күрсәтә, әйтә. ("Чиста туп", "Пычрак аю"...).
Эш дәфтәрендәге 13 нче биремне кулланып була.

3. ***Дидактик уен "Курчакка бүләк".***

Тәрбияче зур курчакка- зур туп, кечкенә курчакка- кечкенә туп бүләк итәргә куша." Мә, зур туп ", "Мә, кечкенә туп".

4. ***Дидактик уен "Дөрес сана".***

Санау күнекмәләрен билгеләү (1-5 кадәр). Тәрбияче уенчыклар, муляжлар санарга тәкъдим итә. Төркемдәге балаларны да санарга була. "Ничә малай?", "Ничә кыз?".

5. ***Дидактик уен "Ничә?".***

Санау күнекмәләрен тикшерү өчен шулай ук, укыту методик комплектындагы күрсәтмә рәсемнәрне дә кулланып була.
- Ничә туп?- Биш туп.

**<u>Югары дәрәҗә (2,7-3)</u>**-әйберләрнең сыйфат билгеләрен, күләмен исем белән кушып дөресәйтә.
**<u>Уртача дәрәҗә (2-2.6)</u>**- 1-2билгесен әйтә.
**<u>Уртачадан түбән дәрәҗә (1-2)</u>**-әйберләрнең билгеләрен, күләмен рус телендә әйтә.

**5.Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сарап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау).**

***1. <u>Уен ситуациясе "Әйдәгез танышабыз".</u>***

"Син кем?" соравына аңлап җавап бирүе билгеләнә. К нам пришла новая кукла, она хочет с вами познакомиться: -Исәнмесез. Мин Алсу. Син кем? (Мин Оля (Коля). -Мин Алсу, мин кыз. Син кыз? (Юк, мин малай (әйе, мин кыз).

***2. <u>Уен ситуациясе "Кунак каршылыйбыз ".</u>***

а) Тәрбияче: К нам идут гости.

***Спроси. "Кто там?". "Кем анда?"***-Мин әби(бабай). ***"Позови бабушку (дедушку)".*** - Әби(бабай)кил монда. ***"Поздоровайся с бабушкой (дедушкой)"***-Исәнме, әби(бабай).

***"Спроси у бабушки (дедушки) как дела?"***-Әби(бабай)хәлләр ничек? -Әйбәт,рәхмәт. ***"Предложи бабушке (дедушке) сесть". -*** Әби(бабай)утыр.

***"Предложи бабушке (дедушке) пить чай"*** -Мә ,чәй,эч. ***Скажи: "До свидания!"*** Сау бул, әби! (бабай).

б) Балага "кунак" белән исәнләшергә, хәлен сорарга, чакырып утыртырга, сыйларга("аша, эч") һәм саубуллашырга тәкъдим ителә.

***1. <u>Уен ситуациясе "Кунакларны сыйла".</u> Угости Акбай хлебом, Мияу молоком***.

-Мә, Акбай ипи, аша. - Рәхмәт. -Мә, Мияу сөт, эч. - Рәхмәт.

Эш дәфтәрендәге 16 нчы биремне кулланып була**.**

***2. <u>Уен ситуациясе "Бер - береңне сыйла ".</u>***

*(Ашамлык муляжлары кулланып)*

***"Угости яблоком".***

- Мә, алма, аша.- Рәхмәт.

***"Спроси, яблоко вкусное?"***

- Алма тәмле?- Әйе, тәмле.

Эш дәфтәрендәге 6 нчы биремне кулланып була**.**

***3. <u>Уен ситуациясе "Уенчыклар илендә"</u>***

***1 . Ты пришел в магазин игрушек. Попроси игрушку, которая тебе нравится***.

-Куян бир (әле).- Рәхмәт.

***2. Предложи поиграть с игрушкой.***

- Мә, туп, уйна. - Рәхмәт.

***3. Позови друга, предложи помыть игрушку.***

-Коля, кил монда.- Мә, туп, ю.

***4. Поменяйтесь игрушками. Попроси у друга игрушку, предложи ему свою***

- Коля, туп бир - Мә, туп.- Рәхмәт.

**<u>Югары дәрәҗә(2,7-3)</u>**-аралаша,сөйләм күнекмәләрен актив куллана.
**<u>Уртача дәрәҗә(2-2,6)</u>**-тәрбияче ярдәмендә аралаша.
**<u>Уртачадан түбән дәрәҗә(1-2</u>**) -аңлый,русча җавап бирә

| № | Баланың исеме, фамилиясе | Биремнәр | | | | | Нәтиҗә | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | баллар | дәрәҗә |
| | | “Минем өем” проекты буенчаөйрәнгәнлексиканысөйләмдәк уллану.(Өйрәнгәнтемаларбуенча дүрт – биш рәсем яисә предметкүрсәтелә,татарчаисемнәренәйт ергәкушыла) | Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”,“саубул”,“рәхмәт”) | Боерыкны аңлап үтәү һәм кулланабелү(кил,утыр,сикер,ю,аша,эч) | Тирә - юньдәгепредметларның сыйфатын, күләменбелдерәторгансүзләрнеаңл апсөйләмдәкуллану. | Аралаша белү(ягымлысүзләр әйтү, чакыру,сыйлау,сарапалу,тәкъдимит ү,инкарьиү,раслау) | | |
| 1. | | | | | | | | |
| 2. | | | | | | | | |

| Нәтиҗәләрне билгеләү | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә 2,7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, сорауларга җавап бирә, яхшы аралаша. |
| Уртача дәрәҗә 2 дән 2,6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, аралашуда бик үк актив түгел. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә 1 дән 2 гә кадә | Аңлый, русча җавап бирә. |

**Уку елы ахырында зурлар, уку елы башында мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының “Уйный-уйный үсәбез” проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү**

**1.“Уйный – уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла)**

1. ***Дидактик уен “Бу нәрсә?”***

(Лексика: аш, ботка, сөт, кашык, тәлинкә, чынаяк).

Уен эчтәлеге: Тәрбияче рәсемнәргә күрсәтеп сорый:

- Бу нәрсә? (“Аш”...)

2. ***Дидактик уен “Кәрзиндә нәрсә бар?”***

(Лексика: кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, алма).

Уен эчтәлеге: Куян кәрзин белән яшелчәләр һәм җиләк-җимеш алып килгән. Куян сорый: “Нәрсә бар?” (“Кәбестә”...)

3. ***Дидактик уен “Нәрсә юк?”.***

(Лексика: кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, алма).

Куян бер яшелчә муляжын яшереп куя: “Нәрсә юк?”. Бала нәрсә юклыгын әйтергә тиеш. Уенны рәсемнәр кулланып та үткәрергә була.

4. ***Дидактик уен “Дөресен әйт”.***

(Лексика: күлмәк, чалбар, сарафан, өстәл, урындык, карават).

Уен эчтәлеге: Балага рәсемнәр бирелә. Бала рәсемнәрнең исемен атый һәм күрсәтә.

**Югары балл(2.7-3)**— сүз байлыгы җитәрлек, яшелчәләр, савыт-сабалар, киемнәр, өйҗиһазлары атамаларын аңлап дөрес күрсәтә, исемнәрен әйтә һәм куелган сорауларга җавап бирә.

**Уртача балл(2-2,6)**-сүз байлыгы бар, кайбер сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.

**Уртачадан түбән балл(1-2)**-аңлый, русча җавап бирә.

**2. Ягымлы сүзләр куллану ("Исәнме", "Сау бул", "Рәхмәт", "Исәнмесез", " Сау булыгыз").**

***Ситуатив күнегүләр (уртанчылар төркемендәге ягымлы сүзләр бүлеген кара):***

а) Поздоровайся с Акбаем.
б) Спроси, как дела у Акбая.
в) Скажи спасибо Акбаю. Спроси, как дела.
г) Попрощайся с Акбаем.
д) Поздоровайся с воспитателем, Мияу и Акбай.
е) Попрощайся с воспитателем, Мияу и Акбай.

**Югары балл (2.7-3)**—бала сөйләмдә ягымлы сүзләрне урынлы куллана.
**Уртача балл (2-2,6)**–уен ситуацияләрен тәрбияче ярдәмендә төзи.
**Уртачадан түбән балл (1-2)**–аңлый,җавап бирә алмый.

**3. Боерыкны бирә белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал).**

Балаларның боерыкларны бирә белү күнекмәләрен тикшерү. Балалар бер-берсенә боерык бирәләр. Саша, аша! – Саша ашау хәрәкәтләре күрсәтә. Алга таба Саша үзе башка балага боерык бирә һәм шундый тәртиптә дәвам итеәлә.
(Лексика: кил, утыр, сикер, ю, аша, эч, уйна, ки, сал).

**Югары балл (2,7-3)**–8-9сүз.
**Уртача балл (2-2.6)**–5-6сүз.
**Уртачадан түбән (1-2)**–1-2сүз.

**4. Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау бирә белү. (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?).**

*1. **Сюжетлы-рольле уен "Кибет"***

Балаларга рус телендә кибет уены үткәрү аңлатыла һәм өч төп сорауны куя белүләрен максат итеп куясың. Уен яшелчә, киемнәр, савыт-саба, өй җиһазлары рәсемнәре кулланып үткәрелә. (Лексика: Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?).

*2. **Дидактик уен "Нинди?".***

Тикшерүдә сорауларны аерым кулланып та үткәрергә була.
Әйберләрне билгесен ачыклау өчен бирелә торган сорауга аңлап җавап бирү һәм ул сорауларны үзлектән куя белү.
(Лексика: нинди? кызыл, сары, яшел, зәңгәр).

*3. **Дидактик уен "Ничә?".***

Санау күнекмәләрен билгеләү (1- 10 кадәр).

*4. **Дидактик уен "Дөрес сана".***

Тәрбияче уенчыклар, муляжлар, укыту методик комплектындагы күрсәтмә рәсемнәрне санарга тәкъдим итә. Балалар бер-берсенә сорау бирәләр һәм җавап бирәләр. Шулай ук, сорауны тәрбияче үзе дә бирә ала. *"Ничә...?".*

**Югары балл (2,7-3)**–диалогта3сорауны да аңлап куллана**.**
**Уртача балл (2-2.6)**–диалогта2сорауны аңлап куллана**.**
**Уртачадан түбән (1-2)**–диалогта1сорауны аңлап куллана**.**

**5. Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау).**

*1. **Уен ситуациясе "Әйдәгез танышабыз".***

"Син кем?" соравына аңлап җавап бирүе билгеләнә.
К вам пришла новая кукла, она хочет с вами познакомиться: -
Исәнмесез. Мин Алсу. Син кем? (Мин Оля яки Коля).
- Мин Алсу, мин кыз. Син кыз? (Юк, мин малай)

*2. **Уен ситуациясе"Кунак каршылыйбыз".***

*3. **Уен ситуациясе "Кибеттә".***

**Югары балл (2,7-3)**–бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә,яхшы аралаша.

**<u>Уртача балл(2-2.6)</u>**– сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша.
**<u>Уртачадан түбән(1-2)</u>**– аңлый, русча җавап бирә.

| № | Баланың исеме, фамилиясе | **Биремнәр** | | | | | **Нәтиҗә** | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | **1** | **2** | **3** | **4** | **5** | **баллар** | **дәрәҗә** |
| | | "Уйный – уйный үсәбез" проектыбуенчаөйрәнгәнлексиканысөйләмдәкуллану.(Өйрәнгәнтемаларбуенчабиш–алтырәсемяисәпредметкүрсәтелә,татарчаисемнәренәйтергәкушыла) | Ягымлы сүзләр куллану("исәнме","саубул", "рәхмәт"."исәнмесез","саубулыгыз") | Боерыкны бирә белу(кил,утыр,сикер, уйна, ю, аша,эч,ки,сал) | Уен ситуацияләрендә үзлектәнсораубирәбелу(Нәрсәкирәк?Ниндиi?Ничә?) | Аралаша белу (ягымлы сүзләрәйтү,чакыру,сыйлау,сорапалу,тәкъдимитү,инкарьитү,раслау) | | |
| 1. | | | | | | | | |
| 2. | | | | | | | | |

| **Нәтиҗәләрне билгеләү** | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә 2,7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша. |
| Уртача дәрәҗә 2 дән 2,6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә 1 дән 2 гә кадәр | Аңлый, русча җавап бирә. |

**Уку елы ахырында мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының**
**"Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар" проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.**
**1."Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар" проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану.**
**(Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла)**

1. ***<u>Дидактик уен "Бу нәрсә?"</u>***

(Лексика: тычкан, бүре, төлке, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, аю).
Уен эчтәлеге: Тәрбияче рәсемнәргә күрсәтеп сорый:
- Бу нәрсә? ("бүре".)

2. ***<u>Дидактик уен "Портфельдә нәрсә бар?"</u>***

(Лексика: китап, дәфтәр, рәсем, мәктәп).
Уен эчтәлеге: Тәрбияче портфельдән рәсемнәр яки предмет алып күрсәтә, исемен сорый: - Портфельдә нәрсә бар?- ("Дәфтәр бар"...)

3. ***<u>Дидактик уен "Портфельдә нәрсә юк?"</u>***

Бала нәрсә юклыгын әйтергә тиеш. Уенны рәсемнәр кулланып та үткәрергә була.

4. ***<u>Дидактик уен "Дөресен әйт"</u>***

(Лексика: чәк- чәк, өчпочмак, бәрәңге, аш, ботка, су).
Уен эчтәлеге: Балага рәсемнәр бирелә. Бала рәсемнәрне атый.
**<u>Югары балл (2.7-3)</u>**—10-14 сүз.
**<u>Уртача балл (2-2,6)</u>**–7-9 сүз.
**<u>Уртачадан түбән балл (1-2)</u>**–1-6 сүз.

**2. Ягымлы сүзләр куллану**
**(“Исәнме”, “Исәнмесез”, “Сау бул”, “Сау булыгыз”, “Рәхмәт”, “Зур рәхмәт”, “Хәерле көн”,“Хәлләр ничек?”, “Әйбәт”)**

***Ситуатив күнегү:***

Телефоннан сөйләшү.

Эш дәфтәрендәге 1 нче биремне кулланып була**.**

**Югары балл (2,7-3)**—бала сөйләмдә ягымлы сүзләрне урынлы куллана.

**Уртача балл (2-2,6)**–тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.

**Уртачадан түбән балл (1-2)**–аңлый, сорауларга җавапны русча бирә.

**3. Боерыкны бирә белү.**

(Лексика: кил монда, утыр, сикер, ю, аша, эч, уйна, ки, сал, йөгер, бие, җырла, йокла).

***Дидактик уен: “Командир”***

Эш дәфтәрендәге 9 нчы биремне кулланып була**.** Бер бала икенче балага боерык бирә. Мәсәлән: -Коля, сикер! (Коля сикереп күрсәтә).

-Коля, син нишлисең? (Колядан сорый) – Мин сикерәм.

-Коля нишли? (Башка баладан сорый) – Коля сикерә.

**Югары балл (2,7-3)**—11-13сүз белән боерык бирә, син нишлисең, нишли сорауларын бирәбелә.

**Уртача балл (2-2,6)**–бары боерык бирә, сорауларны куя алмый.

**Уртачадан түбән балл (1-2)**–1-5сүз белән боерык бирә, сорауларны русча әйтә.

4. **Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау бирә белү.**
   **(Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? Нишли? Кая барасың?)**

   1. ***Уен ситуацияләре:***

а) “Кибет” (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?)

б) “Телефоннан сөйләшү” (Кая барасың? Син нишлисең?)

в) “Танышу” (Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? Нишли?)

   2. ***Сюжетлы-рольле уен “Кибет”***

Балаларга рус телендә кибет уены үткәрү аңлатыла һәм өч төп сорауны куллана белүләре тикшерелә. Уен яшелчә, киемнәр, савыт-саба, өй җиһазлары, йорт кошлары, уенчык рәсемнәре кулланып үткәрелә.

(Лексика: Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?).

   2. ***Дидактик уен “Нинди?”.***

Тикшерүдә сорауларны аерым кулланып та үткәрергә була.

(Лексика: кызыл, сары, яшел, зәңгәр, ак, кара).

   3. ***Дидактик уен “Сана”.***

Санау күнекмәләрен билгеләү (1- 10 кадәр).

**Югары балл (2,7-3)**–сорауларны аңлап куллана**.**

**Уртача балл (2-2,6)**–аңлый, тәрбияче ярдәме белән куллана**.**

**Уртачадан түбән (1-2)**–русча җавап бирә.

**5. Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау)**

1. ***Уен ситуациясе “Әйдәгез танышабыз”***
   - Исәнмесез. Син кем? - (Мин Оля яки Коля).
   - Мин кыз. Син кыз? - (Юк, мин малай).
   - Сиңа ничә яшь?- (6 (7) яшь).
2. ***Уен ситуациясе “Телефоннан сөйләшү”.(диалогны сан, сыйфат, күләм берәмлеге кертеп баетырга була)***
3. ***Уен ситуациясе“Кая барасың?”*** (*мәктәп,кафе,цирк һ.б.*)4.***Ситуатив күнегү.***

а) Син нишлисең?

- Мин биим (утырам, сикерәм, ашыйм, эчәм, уйныйм, йөгерәм, җырлыйм, йоклыйм).

**<u>Югары балл (2,7-3)</u>**– бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша.

**<u>Уртача балл (2-2.6)</u>**– сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша. **<u>Уртачадан түбән (1-2)</u>**– аңлый, русча җавап бирә

| № | Бала ның исеме, фамилиясе | **Биремнәр** | | | | | **Нәтиҗә** | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | **1** | **2** | **3** | **4** | **5** | **баллар** | **дәрәҗә** |
| | | “Без инде хәзер зурлар,мәктәпкәилтәюллар”проект ыбуенчаөйрәнгәнлексиканысөйләм дәкуллану.(Өйрәнгәнтемаларбуенч абиш–алтырәсемнисәпредметкурсәтелә,та тарчаисемнәренәйтергәкушыла) | Ягымлы сүзләр куллану(“исәнме”,“исәнмесез”, “сау бул”, “сау булыгыз”, “рәхмәт”,“зуррәхмәт”,“хәерле көн”,“хәлләр ничек?”, “әйбәт”) | Боерыкны бирә белү(кил,утыр,сикер,уйна, ю, аша,эч,ки,сал,бие,җырла,йөгер,йокла) | Уен ситуацияләрендә үзлектәнсораукуябелү.(Нәрсәкирәк?Нинди?Ничә?Синкем?Букем?Бунәрсә?Нишли?Каябарасың?) | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу,тәкъдимитү,инкарьиү,раслау) | | |
| 1 | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | |

| **Нәтиҗәләрне билгеләү** | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә 2,7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша. |
| Уртача дәрәҗә 2 дән 2,6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә 1 дән 2 гә кадәр | Аңлый, русча җавап бирә. |

# II. Эчтәлекле бүлек

Өлкәннәр һәм балаларның белем бирү өлкәсендә катнашучылар тарафыннан формалаштырыла торган төп белем бирү программасының бер өлешен тормышка ашыру һәм үзләштерү буенча эшчәнлеге ике төп модель – өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлеге һәм балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге белән оештырыла. Өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлеге кысаларында белем бирү мәсьәләләрен хәл итү турыдан-туры белем бирү эшчәнлегендә дә (режим моментларын бер үк вакытта үткәрү белән бәйле булмаган), шулай ук режим моментларында (балаларның иртән килү, йөрү, ризык кабул итүгә әзерлек, көндезге йокы) гамәлгә ашырыла.

### 2.1. Балага үсеш юнәлешләре буенча белем бирү өлкәләре

| Юнәлешләр | Белем бирү өлкәләре | Эшчәнлек төрләре | |
|---|---|---|---|
| Социаль-коммуникатив үсеше | Социальләштерү | -сюжетлы-рольле уеннар- әңгәмәләр<br>-мультфильмнар карау | Экологик культура, табигатькә аңлы караш тәрбияләү;<br>балаларда хезмәткә |
| | Хезмәт | Хезмәт эшчәнлеге | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | турындага балалар әдәбияты белән таныштыру | карата уңай мөнәсәбәт формалаштыру;үз тормышыңның куркынычсызлыгы нигезләрен аңлату. |
| | Иминлек | - уен барышында куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү | |
| Танып-белү үсеше | Танып белү | - экскурсияләр<br>- дәфтәрләрдә эш<br>- күрсәтмә әсбаплар буенча эш (санау,төсен, формасын, зурлыгын әйтү) | Туган як табигате, үсемлекләре, җәнлекләре белән танышу; |
| Сөйләм үсеше | Матур әдәбият белән таныштыру | -әкиятләр сәхнәләштерү, шигырьләр уку<br>-мультфильмнар карау | Нәфис сүз, халык авыз иҗаты, әдәби әсәрләр, милли бәйрәмнәр аша балаларның сөйләм телен баету, уй-фикерләрен билгеле бер эзлеклелектә җиткерә белүләренә ирешү. |
| | Аралашу | - ситуатив күнегүләр<br>- сюжетлы-рольле уеннар<br>- хикәяләр төзү, әңгәмәләр | |
| Иҗади-сәнгать үсеше | Иҗат | - дәфтәрләрдә эш<br>- рәсем ясау, ябыштыру, әвәләү | Балаларның милли сынлы сәнгать турындагы белемнәрен баету, татар һәм Идел буе халыкларының декоратив-гамәли сәнгать үрнәкләре белән таныштыру, милли орнамент белән кием-салым,савыт-саба бизәргә өйрәтү; күренекле композиторларның, төрле халыкларның җырлары, биюләре |
| | Музыка | - җырлар<br>- музыкаль-дидактик уеннар<br>- җырлы-биюле уеннар (“Шома бас” дискыннан)<br>- драма уеннары | |
| Физик үсеш | Сәламәтлек | - бармак уенары<br>- туплар белән уеннар<br>- психогимнастика | Идел буе халыкларының хәрәкәтле уеннары аша балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту. |
| | Физкультура | -хәрәкәтле уеннар<br>-зиһен сынаш уеннары<br>- җырлы-биюле уеннар | |

**2.1.1.Социаль-коммуникатив үсеш.** Балаларның социаль характердагы беренчекүзаллауларын булдыру һәм балаларны социаль мөнәсәбәтләр системасына кертү; хезмәткә уңай мөнәсәбәт формалаштыру; үз тормышыңның куркынычсызлыгы нигезләрен һәм экологик аң (әйләнә – тирә дөнья куркынычсызлыгы) алшартларын формалаштыру максатларын тормышка ашыра. Балаларның Татарстан Республикасы, анда яшәүче

халыклар, аларның хезмәте һәм профессияләре, туган як табигате турында белемнәрен уен эшчәнлеге вакытында тирәнәйтү.Балаларда патриотизм хисләре; үзен туган шәһәре (авылы), республикасы, иленең гражданины итеп тану; шәһәр, республика, ил символикасына (флаг, герб, гимнга) хөрмәт белән карауны һәм горурлану хисе тәрбияләү. Иҗтимагый чыгышы, расасы, теле, дине, җенесе һәм яшенә карамыйча, янәшәдә яшәүчеләргә (балаларга, өлкәннәргә) уңай мөнәсәбәт, түземлек (толерантлык); башка кешеләрнең хисләре, фикерләре, теләкләренә, карашларына хөрмәт тәрбияләү, үзенең башкалар фикере белән риза булмавын дәлилли яисә үз позициясен яклый белергә өйрәтү. Башка ил, этнос халыклары белән позитив аралашуның, хезмәттәшлек итүнең мәгънәсен аңлату. Якындагы социумда үз урыны, теге яки бу төркемдәге кешеләргә нинди мөнәсәбәттә булуы (балалар бакчасындагы төркем яисә бию түгәрәге әгъзасы, спорт мәктәбе укучысы,булачак гимназист һ. б.) турында күзаллаулар формалаштыру. Гаилә тарихына (карт бабай, бабай, карт әби, әби) карата кызыксыну тәрбияләү. Гаиләң белән горурлану хисләре, гаилә әгъзаларының уңышларына сөенү, бүләкләрен игътибарсыз калдырмау күнекмәләре тәрбияләү. Идел буе халыкларының әдәби әсәрләре, нәфис һәм мультипликацион фильмнары, әйләнә-тирәдәге тормыш турындагы күзаллауларын сюжетлы-рольле һәм режиссёрлык уеннарында иҗади куллануларына булышлык итү. Балаларның сәхнәләштерү һәм кую өчен Идел буе халыкларының әкиятләрен, шигырьләрен, җырларын, биюләрен мөстәкыйль сайлап алуларын хуплау; куелачак спектакльгә кирәкле атрибутлар һәм декорацияләр әзерләргә, үзара вазифаларны билгеләргә һәм рольләр бүлешергә булышу. Театральләшкән эшчәнлектә театрның төрле төрләрен (бибабо, бармак, курчак, рәсемнәр һ. б. театрлар) куллану. Сәхнә сәнгатенә карата кызыксыну үстерү. Коллективта сүзле уеннар уйнарга омтылышларын хуплау. Идел буе халыклары уеннарын уйнау тәҗрибәсен баету.

**2.1.2. Танып-белү үсеше.** Балаларда танып белү ихтыяҗларын һәм акылны үстерү;ТатарстанРеспубликаның төп символикасы, географик урыны, анда яшәүче халыкларның традицияләре, гореф–гадәтләре, йолалары белән таныштыру; туган як табигате турындагы белемнәрен киңәйтү, туган якта ешрак очрый торган үсемлек һәм хайваннарга карата кызыксынуны үстерү максатларын тормышка ашыра.Туган як тарихы, мәдәнияты, сынлы сәнгать, туган якның табигате белән таныштыру исәбенә балаларның күзаллауларын киңәйтү. Туган як табигате, климаты, кешеләренең тормышы белән таныштыруны дәвам итү. Үз шәһәренең (авылының) истәлекле урыннары, халык һөнәрләре, милли кухня, Татарстан Республикасы халыкларының тел культурасы белән таныштыру. Картада туган шәһәрен, республикасын, башкаланы, Татарстандагы эре шәһәрләрне (Әлмәт, Яр Чаллы, Түбән Кама, Бөгелмә, Яшел Үзән һ. б. ны) күрсәтә һәм атый белергә өйрәтү. Борынгы шәһәрләр (Биләр, Болгар), аларның тарихы,культурасы, көнкүреше белән таныштыру. Авыл һәм шәһәр кешеләренең көнкүрешен чагыштырырга өйрәтү. Татар һәм рус халкының яши торган өе, йорт кирәк-яраклары, өс киемнәре үзенчәлекләренә игътибар итү. Туган шәһәрендә бара торган позитив үзгәрешләрне (балалар бакчалары, спорт комплекслары, театрлар һ. б. төзелү) күрә белергә өйрәтү. Казанның эре промышленность һәм сәүдә үзәге булуы, татар халкының элек-электән игенчелек, терлекчелек, күн эшкәртү, сәүдә белән шөгыльләнүе турында балаларга сөйләү. Туган шәһәренең, башка шәһәрләрнең символикасын өйрәнүне дәвам итү, үз халкының бер өлеше булуын аңлый белергә ярдәм итү. Милли һәм дөнья культураларының үткәненә һәм бүгенге сенә балаларны якынайту. Музыка һәм театр сәнгатенең күренекле шәхесләре, аларның тормыш һәм иҗат юллары белән таныштыру (композиторлар: С. Садыйкова, С. Сәйдәшев, Ф. Яруллин һ. б., җырчылар: Ф. Шаляпин, И. Шакиров, Р. Ибраһимов һ. б., театр режиссёрлары: М. Сәлимҗанов, К. Тинчурин һ. б., В. Качалов, Г. Камал исемендәге театр актёрлары һ. б.). Аларның тормышларына һәм эшчәнлекләренә кызыксыну уяту. Күренекле фән эшлеклеләренең тормышы һәм эшчәнлекләре белән таныштыру (Н. И. Лобачевский, К. Ф. Фукс, И. М. Симонов, Н. Н. Зинин, А. М. Бутлеров, А. Е. Арбузов һ. б.). Балаларның танып белүгә карата кызыксынуларын канәгатьләндерү,Казан(Идел буе)федераль университеты укытучыларыһәм аны тәмамлаучылар турында мәгълүмат бирү.Милләтебез каһарманнарының Бөек Ватан

сугышында күрсәткән батырлыклары турында сөйләү (М. Җәлил, Г. Гафиятуллин, М. П. Девятаев, П. М. Гаврилов, Н. Г. Столяров һ. б.). Әти-әниләрне балаларга әби һәм бабаларының сугышта алган бүләкләре турында сөйләргә җәлеп итү. Ватанны саклаучыларга карата хөрмәт хисләре тәрбияләү (һәйкәлләр, обелискларга чәчәкләр кую һ. б.). Табигатьне саклау буенча балаларның белемнәрен тирәнәйтү. Туган якның тере һәм тере булмаган табигатенә сакчыл караш тәрбияләү, табигатькә катнашуыңнан соң туган уңай һәм тискәре нәтиҗәләрне алдан күрә белергә өйрәтү, табигатьнең ресурсларына сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү, аны рациональ файдалану күнекмәләре формалаштыру. Үсемлек һәм җиләкләрне җыю кагыйдәләре белән таныштыру. Дәүләт тыюлыклары, анда яшәүче тереклек ияләре, Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән үсемлек (флора) һәм хайваннар (фауна) төрләре белән таныштыруны дәвам итү. Хайваннар һәм үсемлекләр дөньясында сирәк очрый торган төрләргә сакчыл караш кирәклеген балаларның аңнарына җиткерү. Татарстанның елга, күлләрендә яшәүче тереклек ияләре белән таныштыру. Кеше тормышында чишмә, елгаларның тоткан урыны, әһәмияте турында сөйләү. Республика сулыкларын чиста тотарга теләк уяту. Туган як табигатенең матурлыгына, андагы форма, ис, төс муллыгына игътибар итү. Табигатьтәге үзгәрешләрне күрә белергә өйрәтү.

**2.1.3.Сөйләм үсеше.** Әйләнә–тирәдәге кешеләрнең үзара мөгамәләсенең конструктив ысулһзм чараларын үзләштерү; балада китап укуда кызыксыну һәм ихтыяҗ формалаштыру максатларын тормышка ашыра. Балаларны матур әдәбият әсәрләре, халык әкиятләре, фольклоры белән таныштыру.Татар теленә карата тотрыклы кызыксыну үстерү. Мәгълүмати аралашу технологияләре, аудио- һәм видеоязмалар, уку-укыту методик комплектлары ярдәмендә предметны, аның билгесен, хәрәкәтен белдерүче сүзләрне актив кулланышка кертү, гади аралашу өчен кирәк булган сөйләм берәмлекләребайлыгы булдыру. Балаларның сүз байлыгын арттыру. Төзелеше ягыннан катлаулы булмаган хикәя һәм сорау җөмләләр төзү күнекмәләрен ныгыту. Үзе турында, бер кеше гамәлләрен сурәтләгән ситуатив картиналар сериясе буенча, сюжетлы рәсемнәр, үз күзәтүләреннән чыгып, зур булмаган (3–5 җөмләле) хикәяләр төзибелергә өйрәтү. Балаларның төрле эшчәнлек вакытында татар халык фольклор әсәрләрен, еш кулланыла торган сүзләр һәм әйтемнәрне файдалануга омтылышларын хуплау. Татар телендә сөйләүче әңгәмәдәшенең сөйләмен тыңлыйбелүне формалаштыру, нәрсә турында сөйләгәнен аңларга тырышу, телне аз белүенә карамастан, аның белән әңгәмәгә кереп, аралашырга омтылышын хуплау. Балаларны татар телен киләчәктә (башлангыч мәктәптә) тагын да аңлабрак, төшенеп өйрәнергә әзерләү.

**2.1.4. Иҗади-сәнгать үсеше.** Балаларда әйләнә–тирәдәге матурлыкка кызыксыну уятуны һәмүзләрен күрсәтү ихтыяҗларын канәгатьләндерүне; балаларның музыкальлекләрен, музыканы, матур әдәбият, фольклор әсәрләрен хис-тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү максатларын тормышка ашыра. Балаларны татар халкының сәнгате (музыка, бию, рәсем сәнгате, матур әдәбият әсәрләре), анда яшәүче атаклы кешеләр белән таныштырып, аларда әхлакый-патриотик хисләр тәрбияләү. Милләтебезнең дини йолалары, халык авыз иҗаты, сынлы сәнгате һәм архитектурасы, музыка сәнгате белән таныштыру балаларда Туган илне ярату хисе тәрбияләргә булыша.Милли орнамент элементлары белән таныштыруны дәвам итү.Балалар белән«яшәү агачы»образын карау.Балаларның игътибарынкомпозициянең үзенчәлегенә (симметриясез),шул ук вакытта төрле төсләр файдаланылганчәчәк бәйләменә юнәлдерү. Төрле материаллар кулланырга, реаль һәм әкияти образларны (Идел буе халыклары әкиятләрендәге геройларны да кертеп) сурәтләүнең төрле ысулларын берләштерергә мөмкинлекләр бирү. Республика тормышында булган истәлекле вакыйгаларны рәсемнәрдә чагылдыра белүләрен хуплау. Балаларның эшләрен бергәләп карау, нәрсә ясаганнары турында сөйли белергә өйрәтү. Балаларга эшләренең тематикасын киңәйтүгә булышлык итү. Актүбә һәм Шәмәрдән уенчыкларын натурадан карап әвәли һәм аларның характерлы үзенчәлекләрен бирә белергә өйрәтү. Ике-өч фигурадан торган скульптура төркемнәрен катлаулы булмаган сюжетларга («Сабантуйда», «Чәй эчкәндә», «Ат чабышлары» һ. б.га) берләштерү. Идел буе халыкларының әдәби әсәрләре геройларын күзаллау юлы белән әвәли белү күнекмәләрен формалаштыру. Туган шәһәре (авылы)

тормышындагы вакыйгаларны чагылдыручы сюжетларны мөстәкыйль сайлый белүләрен активлаштыру. Башка белем бирү өлкәләренең эчтәлеге белән ярак-лаштырып, балалар эшләренең тематикасын киңәйтү. Балаларны Г. Тукай әсәрләре һәм аның иҗатын чагылдыручы сәнгать төрләре (Ф. Яруллинның «Шүрәле», Ә. Бәшировның «Су анасы» балетлары, Н. Җиһановның «Кырлай» симфониясе, Б. Урманче, И. Казаков, Б. Әлменов, Ф. Әминов һ. б. ның сынлы һәм рәсем сәнгатьләре әсәрләре) белән таныштыруны дәвам итү. Сәнгатькә карата уңай карашформалаштыру. «Казан» милли-мәдәни үзәгенең милли-мәдәният музеенда булу, анда борынгыдан сакланып калган өй кирәк-яраклары: көмеш подនослар, савыт-саба, бизәк төшерелгән бакыр кувшиннар, комганнар, йорт хайваннары фигуралары формасындагы бронза йозаклар; җәмәгать биналарының интерьерларын һәм экстерьерларын бизәүче декоратив композицияләр белән таныштыру. Борынгы бизәнү әйберләрен: йөзекләр, алкалар, беләзекләр, чулпылар, яка чылбырлары, хәситәләр һ. б.ны карау. Хәзерге заман рәссам-ювелирларның (И. Фазылҗанов, С. В. Ковалевская, В. О. Ковалевский һ. б.ның) иҗатлары белән таныштыру. Балаларның игътибарын бизәнү әйберләренең милли үзенчәлекләренә юнәлдерү. Татар халкының үзенчәлекле сәнгати һөнәре булган укабелән чигү турында сөйләү. Чигелгән түбәтәйләр, хатынкызның бәрхет аяк киеме, күкрәкчәләр, калфаклар һ.б.ны карау. Бигрәк тә популяр булган композицияләргә – «алтын каурый», чәчәк бәйләме, кошлар, бодай башагы, йолдызлар һәм ярымай мотивларына һ.б.га игътибар итү. Туган шәһәр (авыл) архитектурасы – мәчет һәм храм архитектуралары (Кол Шәриф мәчете, Раифадагы Богородицкий ир-атлар монастыре) белән таныштыру эшен дәвам итү. Балаларны татар халкының музыка культурасына якынайту. Татар композиторларының музыкаль әсәрләрен тыңлау. Татарстан Республикасы, Россия Федерациясенең Дәүләтгимннары белән таныштыру. Горурлык хисләре тәрбияләү.

**2.1.5.Физик үсеш.** Балаларның сәламәтлеген саклау,аларда сәламәтлек культурасынигезләрен формалаштыру; физик культура эшчәнлегенә кызыксыну һәм аңлы караш, гармонияле физик үсеш формалаштыру максатларын тормышка ашыра. Татар халык хәрәкәтле уеннарын, физминуткалар кулланып балаларның хәрәкәт активлыгын үстерү, татар халык бәйрәмнәре, халык уеннары аша балаларның физик үсешен камилләштерү.Чәй янына бирелә торган милли камыр ризыклары: гөбәдия (дөге, йөзем һәм йомырка белән), кабартма, бавырсак, талкыш-кәләвә, чәкчәк, кош теле белән таныштыру. Хәрәкәтле халык уеннарын үзгәртеп төрләндерү күнекмәләре бирү. Милли уен-ярышларда («Таяк тартыш», «Аркан тартыш», «Капчык белән сугыш» һ.б.да) катнашасы килү теләге уяту. Кеше тормышында спортның әһәмияте турында күзаллау формалаштыру. Милли спорт төре – көрәш белән таныштыру. Спорт өлкәсендәге билгеле уңыш-казанышлар белән таныштыру. Идел буе халыкларының төрле эчтәлекле уеннарын мөстәкыйль эшчәнлек вакытларында файдалана белү күнекмәләрен ныгыту. Хәрәкәтле уеннарда балаларда көч, җитезлек, кыюлык, тәвәккәллек, түземлек кебек сыйфатлар тәрбияләү. Уен нәтиҗәсен гадел бәяли белүләрен хуплау. Халык уеннары белән кызыксынуларын үстерү.

**2.2.Программаны тормышка ашыруда төрле технологияләр, формалар һәм чаралар**

Программа бурычларын үтәүдә эш формаларының, практик гамәли алымнарның, чараларның әһәмияте зур.

**Төрле эшчәнлекләрдә белем бирү формалары**

| Хәрәкәт | Уен | Хезмәт | Танып-белү | Аралашу |
|---|---|---|---|---|
| -уен<br>-хәрәкәт элементларын кулланыпәңгәмә үткүрү<br>-физминуткалар | -күзәтү<br>-уку<br>-уен<br>-әңгәмә<br>-күмәк уен (тәрбияче; балалар белән)<br>-сюжетлы-рольле уен | -күмәк эшчәнлек<br>-әңгәмә<br>-карау<br>-уен<br>-дежур тору | -күзәтү<br>-сюжетлы-рольле уен<br>-хикәя<br>-үстерүле уен<br>-әңгәмә<br>-ситуатив сөйләшү | -уку<br>-хикәя<br>-әңгәмә<br>-өстәл театры<br>-балалар белән аралашу<br>-шигыр ятлау<br>-уен (дидактик, театральләштерелгән, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | -кагыйдәле<br>уен<br>-экскурсия<br>-бәйрәм | | -уку | режиссер)<br>-табышмакларга җавап табу<br>-текстлы хәрәкәтле уен<br>-тәрбияче белән аралашу |
| Матур әдәбият, фольклорны кабул итү | Рәсем | Музыка | Төзү | |
| -уку<br>-әңгәмә<br>-хикәя<br>-уен<br>-викторина<br>-инсценирование | -карау<br>-уен<br>-бизәү<br>-күргәзмәләр<br>-ясау | -музыка<br>тыңлау<br>-җырлы-<br>биюле<br>уен<br>-җырлау | -уен<br>-күзәтү<br>-карау | |

**Татар телен өйрәтүдә кулланыла торган чаралар:**
1.Эшчәнлек эшкәртмәләре, диагностик материаллар.
2.Тавышлы күрсәтмәлелек (һәр проект өчен аудиоязмалар, анимацион сюжетлар, мультфильмнар).
3.Картиналы һәм картиналы-дидактик күрсәтмәлелек(таратма һәм күрсәтмә рәсемнәр, җырлы-биюле уеннар, театр эшчәнлеге өчен материаллар.
4.Символик, график күрсәтмәлелек (пиктограммалар).
5.Күләмле күрсәтмәлелек (макетлар, муляжлар, уенчыклар)
6.Интерактив уеннар.
7.Эш дәфтәрләре.

**Аралашуга чыгу өчен нәтиҗәле чаралар**

**Аудиоязмалар**

Аудиоязмалар яңа сүз өйрәтү, сөйләм үрнәкләре үзләштерү, уеннар, кыска җырлар өйрәтү, өстәл театры күрсәтү вакытларында куллану өчен кулай. Аларны һәр эшчәнлектә куллану мөһим түгел.

**Яңа сүзләр өйрәтү технологиясе**

Балаларны татар телендә сөйләшергә һәм аралашырга өйрәтү билгеле бер күләмдәге сүз байлыгы булдырудан башлана. Яңа сүзләр үзләштерү процессында махсус сайлап алынган күнегүләр төп чара булып тора. Юнәлеше һәм характеры ягыннан лексик күнегүләрне икегә бүлеп карыйлар: әзерлек күнегүләре һәм сөйләм күнегүләре. *Әзерлеккүнегүләре* балаларны яңа сүзләрне файдаланып сөйләргә әзерли.Бу күнегүләр лексикберәмлекләрне хәтердә калдырырга ярдәм итәләр. *Сөйләм күнегүләре* лексик күнегүләрнең бер төре буларак, үзләштерелгән лексик берәмлекләр җирлегендә ситуацияләргә бәйле сөйләм эшчәнлеген барлыкка китерәләр. Яңа сүз өйрәтү төп методик алымнарның берсе булып тора:

-яңа сүз тәрбияче тарафыннан ачык, төгәл итеп күрсәтмә рәсем ярдәмендә әйтелә;-аудиоязмадан тыңлатыла, кабатлатыла;
-ишеткән сүзне бала рәсемннән табып күрсәтә һәм әйтә;
-сүзләр тизрәк истә калсын өчен сүз кат-кат әйттерелә, аңлашылмаган очракта, аның русча тәрҗемәсе бирелә;
-төрле эш формаларында (пышылдап, күмәкләп, төркемнәргә бүленеп, хәрәкәтләнеп әйтеп) өйрәтелә;
-уеннар кулланып (“Ватык телефон”, “Кайтаваз”...) ныгытыла;
-яңа сүз, таныш булган сүзләр белән грамматик конструкцияләрдә ныгытыла, мәсәлән: зур туп, чиста туп;
-аралашуда кулланыла (бала өйрәнгән яңа сүзләрне, конструкцияләрне бары аралашуда аңлап куллана);

-бала теге яки бу сүзне аның төгәл мәгънәсен аңлап үзләштереп калсын өчен телдән инкарь итү яисә раслау күнегүләре үткәрергә мөмкин;
-өйрәнелгән сүзләрне хәтердә калдыру максатыннан төрле уеннар оештырырга була: “Исемен әйтсәң бирәм”, “Мин күрсәтәм, син әйт”, “Сорап ал”, “Серле кәрзин” һ.б.

Баланың сөйләмен оештыру өчен исемнең алмашлык (мин, син, бу), сан (1 дән 10 га), сыйфат (тәм, күләм, төс, эчке сыйфатлар) һәм фигыль белән бәйләү грамматик конструкцияләре кулланыла. Фигыль белән таныштыру боерык фигыльләрдән башлана (бар, сикер, аша һ.б.). Уртанчылар төркемендә балаларга боерык фигыльләрне аңлап үтәүләрен таләп ителә. Зурлар төркемендә балалар кайбер боерыкларны үзләре бирә (сикер, аша, уйна) һәм аңлап үтиләр. Мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә балалар үзлектән Нишли? Син нишлисең? сорауларын бирәләр һәм аңлап җавап кайтаралар.

**Диалогик сөйләм**

Программаның төп асылы булып аралашуга чыгу тора. Аралашуга чыгу өчен диалогик сөйләмнең әһәмияте бик зур. Диалогик сөйләмгә өйрәткәндә гадидән катлаулыга дигән дидактик принципка таянып эшләү кулай. Диалогик сөйләмдә иң отышлы алым – сорау-җавап рәвешендә (сорау-информация алу берәмлеге) һәм теләк белдерә торган: теләк, үтенү, тәкъдим итү, ризасызлык төсмере булырга мөмкин. Еш кына сораудан соң, әңгәмәдәшнең җавап репликасы килә,раслау яисә инкарь рәвешендә булырга мөмкин.Реплика-җавап сорау рәвешендә дә булырга мөмкин: *Нинди әти?* Бу вакытта әңгәмәдәшнең җавабы тулы да, ким дә булырга мөмкин: *Матур әти;* яисә: *Матур.*

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга ситуатив - тематик принцип нигезендә, диалогик сөйләмне үстерү буенча түбәндәге типтагы күнегүләр тәкъдим итәргә мөмкин:
- уен ситуацияләрендә катнашу;
- тәкъдим ителгән үрнәк буенча кечкенә диалоглар төзү;
- тематик диалоглар төзү;
- сәхнәләштерүдә катнашу;
- рольләргә бүлеп сөйләү.

Диалоглар белән эшләү коммуникатив юнәлештә алып барылырга тиеш. Тәрбияче аларның балалар сөйләменә кирәрлек кирәкле формаларын эшләргә һәм төрле шартларда куллану мөмкинлеген исәпкә алырга тиеш. Тәрбияче, сөйләмгә эмоциональ бизәлеш өстәү өчен, төрле формаларны кулланырга; эш эчтәлегенә туры килә торган интонация, ишарәләр, мимикалардан файдаланырга һ.б. өйрәтергә тиеш. Шул ук вакытта, диалогны сорау бирү һәм аңа җавап алу дип кенә уйларга ярамый. Балаларны диалогик сөйләмгә хас булган башка (сорау һәм җаваплардан тыш) ситуацияләр, репликалар, көндәлек аралашу формаларына да өйрәтергә кирәк.

Аралашуга чыгу өчен нәтиҗәле чаралар булып аудиоязмалар, эш дәфтәрләре, анимацион сюжетлар тора.

**Эш дәфтәрләре**

Эш дәфтәрләре эшчәнлектә өйрәнелгән материалны ныгытуны күздә тотып төзелгән. Дәфтәрләр белән эшләгәндә балалар кабатлыйлар, бер-берсенә сораулар бирәләр, тәрбияче белән аралашалар. Балалар үзләренең эш дәфтәрләрен өйгә алып кайтып өйрәнелгән материалны кабатлый алалар. Бу дәфтәрләр белән әти-әниләр дә, төркем тәрбиячеләре дә эшли ала, чөнки биремнәр рус телендә язылган. Дәфтәрдәге эшнең нәтиҗәсе уртанчылар төркемендә сүзне ишетеп, аңлап, предметларны табып, парлаштырып, чагыштырып, аларның сыйфатын, санын билгеләүгә китерсә, зурлар төркемендә балаларны үзара аралашуга этәрә һәм бу мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә дәвам итә. Иң катлаулы биремнәр мәктәпкә әзерлек төркеме өчен төзелгән. Бу төркемдә хәрәкәтне белдерүче сүзләр, яки фигыльләр күп кулланыла. Балаларны ситуацияләргә куеп, сораулар биреп диалогка этәрәбез. Берүк вакытта, фигыльләр боерык формада (утыр, уйна һ.б.), 2-нче зат алмашлыгына тәңгәл формада (яки утыра, укый, шуа, ашый һ.б.), һәм дә инде үзе турында 1-нче зат алмашлыгын кулланып өйрәтелә (уйныйм, утырам, барам, эчәм һ.б.). Балалар бер-берсенә, өлкәннәргә сораулар бирергә өйрәнәләр: бу нәрсә, нишли, син нишлисең, нәрсә кирәк, нинди һ.б.

Җөмләләр төзү баланың уйлавын таләп итә, чөнки алар 3-4 сүздән торалар. Мәсәлән: Аю караватта йоклый. Куян чана шуа. Песи бит юа һ.б.. Мәктәпкә әзерлек төркемендә өченче бирем җыр формасында бирелә.Бу биремнәрне интерактив такта һәм экраннарда эшләп була.

**Анимацион сюжетлар**

Анимацион сюжетларбалаларның белгән сүз байлыгына, яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән. Сюжетны караганнан соң, балалар белән әңгәмәләр үткәрелә, алда өйрәнелгән уен ситуацияләрен кабатларга тәкъдим ителә.

**2.2.1. Тәрбияче белән балаларның бердәм эшчәнлеге.**

| № | Эш төрләре | Үткәрү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Программа материалларын үзләштерү дәрәҗәсенең мониторингы | Октябрь 2024 ел.<br>Апрель 2025 ел | Татар теленә өйрәтүче тәрбияче |
| 2. | Сәләтле балаларны төрле бәйгеләрдә, бәйрәмнәрдә катнаштыру | Сентябрь - май. | Татар теленә өйрәтүче тәрбияче |
| 3. | Татар халкының, Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның милли йолалары, гореф гадәтләре белән танышу, бәйрәмнәр, кичәләр, төрле чаралар оештыру | Сентябрь - май. | Татар теленә өйрәтүче тәрбияче |
| 4. | Балаларны Г.Тукай әсәрләре белән таныштыруның системалы эшен дәвам итү (мультфильмнар карау, балаларның рәсемнәре...) | Сентябрь - май. | Татар теленә өйрәтүче тәрбияче |
| 5. | Татар язучылары һәм Татарстан Республикасында яшәүче башка халыкларның әсәрләре һәм караган мультфильмнар буенча балалар белән күмәк эш әзерләү. | “Идел буе көненә” | Татар теленә өйрәтүче тәрбияче |
| 6 | Укыту эшчәнлеге дәверендә гаиләдә балалар белән региональ компонентларны күз алдында тотып укыту- тәрбия процессын оештыру. | Сентябрь - май. | Татар теленә өйрәтүче тәрбияче, тәрбиячеләр |

**2.2.2. Педагоглар белән бердәм эшчәнлек.**

| № | Эшчәнлек төре | Үткәрү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Тәрбиячеләр белән дәүләт телләренә өйрәтү буенча консультацияләр, әңгәмәләр үткәрү. | Сентябрь - май | Татар теле тәрбиячесе |
| 2. | “Татарстан Республикасында дәүләт телләре һәм башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законын өйрәнү,тәрбиячеләр белән “Туган җирем Татарстан” почмагына | Сентябрь 2024 ел | Татар теле тәрбиячесе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | куелган таләпләр белән танышу | | |
| 3. | 6-7 яшьлек балаларны татар теленә өйрәткәндә яңа белем бирү технологияләре, мультимедия ресурслары куллану.<br>Мәктәпкә әзерлек төркеме тәрбиячеләре өчен консультация әзерләү. | Ел дәвамында. | Татар теле тәрбиячесе |
| 4. | Төркемнәрдә предметлы-үстерүле тирәлекне баету буенча тәрбиячеләр белән эш үткәрү. | Сентябрь - май. | Татар теле тәрбиячесе |
| 5. | УМКны бөтен юнәлешләрдә дә реализацияләү һәм куллану буенча мастер-класслар үткәрү | Сентябрь - май. | Татар теле тәрбиячесе |
| 6. | Педсоветларда чыгышлар | Ел дәвамында | Администрация, специалистлар, тәрбиячеләр. |

**2.2.3. Балалар бакчасында тәрбияләнүче балаларның гаиләләре белән үзара бәйләнеш**

| № | Эш төрләре | Вакыты | Җаваплы кеше | Үтәлү турында билге |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Бәйрәм иртәләренә әзерләнүдә ярдәм күрсәтү. | Ел дәвамында | Татар теленә өйрәтүче тәрбияче, тәрбиячеләр. | |
| 2. | «Татарча сөйләшәбез” стендларындагы мәгълүматны вакытында алыштырып тору | Ел дәвамында | Татар теленә өйрәтүче тәрбияче | |
| 3. | Әти-әниләр җыелышында катнашу | Сентябрь | Мөдир, өлкән тәрбияче, татар теленә өйрәтүче тәрбияче | |
| 4. | Балаларны татар теленә, туган телгә өйрәтү буенча әти-әниләр белән индивидуаль консультацияләр, әңгәмәләр. | Ел дәвамында | Татар теленә өйрәтүче тәрбияче | |
| 5. | Балалар бакчасында конкурс эшчәнлеген оештыру, әти-әниләрне ике дәүләт телен өйрәнүдә активлаштыру (рәсем конкурслары, мультфильмнар, шигырьләр, әкиятләр буенча кул эшләре конкурсы, шигырь сөйләүчеләр бәйгесе). | Ел дәвамында | Татар теленә өйрәтүче тәрбияче, өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр. | |

# III.Оештыру бүлеге

**3.1. Баланың үсешен тәэмин итү өчен психологик-педагогик шартлар тудыру**

Программа яшь һәм индивидуаль мөмкинлекләре һәм мәнфәгатьләре нигезендә баланың үсешен тәэмин итә торган түбәндәге психологик-педагогик шартлар булдыруны күздә тота.

1.**Өлкәннәр белән балаларның үзара хезмәттәшлеге**, балаларга эшчәнлек, партнер, сайлау мөмкинлеге бирелә торган ситуацияләр тудыруны күздә тота; яңа белемнәр һәм тормыш күнекмәләрен үзләштергәндә аның шәхси тәҗрибәсенә таяну тәэмин ителә.

2. **Педагогик бәяләүнең балалар уңышының чагыштырма күрсәткечләренә ориентлашуы**, ягъни баланың хәзерге һәм алдагы казанышларын чагыштыру, үзбәяне стимуллаштыру.

3. **Уенны бала үсешенең мөһим факторы буларак формалаштыру**.

4. **Физик, социаль-коммуникатив, танып-белү, сөйләм, сәнгать-эстетик үсеш** һәм аныңиндивидуальлеген саклап калуга ярдәм итә торган белем бирү мохите булдыру.

5.**Репродуктив** (әзер үрнәкне яңадан җитештерүче) **һәм продуктив** (субъектив яңа продукт җитештерә торган) **эшчәнлек**, ягъни, балалар эзләнүе, иҗади эшчәнлекне үзләштерү.

6. **Гаилә белән узара мөнәсәбәттә булу**, мәктәпкәчә яшьтәге баланың тулы үсеше өченкирәкле шарт булып тора.

7. **Педагогларның һөнәри үсеше**, шул исәптән баланың осталыгын дәлилләү һәмкоммуникатив компетентлыгын үстерүгә, шулай ук интернеттан куркынычсыз файдалану кагыйдәләрен белүгә юнәлдерелгән.

**3.2. Үстерелешле – предметлы тирәлек оештыру үзенчәлекләре**

Татар телендә дөрес сөйләшергә өйрәтү өчен, балаларны кызыксындыра алырлык аралашу даирәсе булдыру, сюжетлы уеннар оештыру, гомүмән, баланың актив сөйләмен үстерү зарур. Тәрбиячегә татар телен өйрәнүче мәктәпкәчә яшьтәге балаларның телне ясалма тудырылган тел мохитендә үзләштерүләрен онытмаска кирәк. Татар телен өйрәтү шөгыльләре өчен балалар бакчасында махсус бүлмә бар. Бу бүлмәдә РФ һәм ТР дәүләт символлары, туган шәһәр, башкаладагы истәлекле урыннарның фотографияләре, татар, рус, чуваш һ.б. халыкларның декоратив-гамәли сәнгать үрнәкләре сүрәтләнгән альбомнар, үстерешле уеннар, татар халык әкиятләренең геройлары, уенчыклар: куян, аю, песи, эт, төрле төстәге һәм төрле зурлыктагы туплар, төрле төстәге күлмәкләрдән курчаклар, Идел буе халыкларының милли киемнәреннән курчаклар, дидактик һәм таратма материаллар,кирәкле мәгълүматларны истә калдырырга ярдәм итә торган схемалар, балалар өчен матур әдәбият, методиккулланмалар, яшелчә һәм җиләк-җимеш муляжлары һ.б. бар.Татар теле бүлмәсендәге уенчыклар зур, ялтыравыклы, балаларны җәлеп итәрлек, уенчыклар аларның буе җитәрлек шкафларда урнаштырылган. Шул вакытта уенчыклар баланың сәламәтлеге өчен куркыныч тудырмыйлар.

| |
|---|
| 1.РФ и ТР символикасы (герб, флаг). |
| 2. РФ и ТР президентларының фотографияләре. |
| 3.Татар, рус, мари, удмурт, чуваш милли киеменнән курчаклар. |
| 4. ТР башкаласы Казан шәһәре турында информацион һәм күрсәтмә материал (альбомнар, китаплар, открыткалар, иллюстрацияләр). |
| 5. ТР турында информацион һәм күрсәтмә материал (шәһәрләр, аларның истәлекле урыннары, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы). |
| 6. Татарстан, Россия, Башкортостан, Чувашия, Удмуртия, Мари-Эл, Мордовия турында информацион һәм күрсәтмә материал (папкалар, дидактик, хәрәкәтле уеннар). |
| 7. Татар язучыларының һәм шагыйрьләренең портретлары һәм әсәрләре. |
| 8. Татар халык әкиятләре. |

| |
|---|
| 9.Татар милли орнаментларының үрнәкләре (7 элемент):<br>лалә, яфрак, кыңгырау, канәфер чәчәге, өч яфрак, чалмабаш, гөлҗимеш. |
| 10. Татар милли орнаментлары белән таныштыру өчен дидактикуеннар:<br>• «Бизәкне төзе»;<br>• «Парын тап»;<br>• «Тап һәм ата»;<br>• «Киемне бизә» (түбәтәй, калфак, читек, камзул һ.б.). |
| 11. Яшелчә һәм җиләк-җимеш муляжлары. |
| 12.Уенчыклар: йорт хайваннары, кыргый хайваннар, савыт-саба, җиһаз, предметлы уенчыклар. |
| 13. УМК буенча дидактик уеннар: «Бер һәм күп», «Кем нәрсә эшли», «Курчакны киендер», |
| «Яшелчәләр», «Жиләк-жимешләр», "Кәрзиндә нәрсә бар?", "Төсе буенча тап", "Бу кем?", "Бу нәрсә?" һ.б. |
| 14.Журналлар: «Салават күпере», «Кучтәнәч». |
| 15.Документация: портфолио, папкалар, диагностика һәм аның өчен инструментарий, анкеталар, планнар: перспектив һәм календарь, еллык, УМКны тормышка ашыру, рус телле тәрбиячеләрне татар теленә өйрәтү.<br>16.Уеннар тупланган папкалар: хәрәкәтле уеннар, халык уеннары, бармак уеннары. |

**3.3. Материаль-техник тәэмин итү**

Куелган максатларга ирешү, бурычларны үтәү өчен материаль-техник шартлар тудырылган.
Татар теле кабинеты балалар бакчасының беренче катында урнашкан. Мәйданы 16 кв.м .
Ноутбук – 1 данә
Проектор – 1 данә
Интерактив такта – 1 данә
Магнитлы такта – 1 данә
Өстәл – 1 данә
Шкафлар – 5 данә
Комод – 1 данә
Балалар өчен урындыклар – 16 данә
Балалар өчен өстәлләр – 4 данә

**Методик материаллар**

Мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре өчен Федераль дәүләт укыту стандартлары таләпләренә җавап бирә алырдай укыту-методик комплектлары булдырылды. Балалар бакчалары андагы балаларны татар теленә өйрәтү, аларның сөйләм телен үстерү өчен заман таләпләренә җавап бирерлек итеп төзелгән эзлекле, максатчан методик әсбаплар белән тәэмин ителделәр.

**1.Таратма һәм күрсәтмә материаллар**

Уртанчылар төркеменең «Минем өем» укыту методик комплекты буенча күрсәтмә, таратма материаллар.

**"Минем өем" проекты буенча 4-5 яшьлек балалар өчен**

| | | |
|---|---|---|
| 1.А4формат ында күрсәтмә рәсемнәр. | «Минем гаилә»<br>Бабай, әби, әти, әни, малай, кыз. | Һәрберсе<br>1 данә |
| | Зур уенчыклар: курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина.<br>Кечкенә уенчыклар: курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина. | Һәрберсе<br>1 данә |
| | «Ашамлыклар»<br>Ипи, алма, чәй, сөт. | Һәрберсе<br>1 данә |
| | «Уенчыклар»<br>Курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина. | Һәрберсе<br>1 данә |

| | | |
|---|---|---|
| | курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина – пычрак уенчыклар. | |
| | Сюжетлы рәсемнәр: «Куян өйгә керә, өйдә аю утыра». «Куян өйдән чыга, саубуллаша». | Һәрберсе 1 данә |
| | Рәсемнәр: 1 куян, 2 куян, 3 куян, 4 куян, 5 куян;<br>1 аю, 2 аю, 3 аю, 4 аю, 5 аю;<br>1 курчак, 2 курчак, 3 курчак, 4 курчак, 5 курчак;<br>1 туп, 2 туп, 3 туп, 4 туп, 5 туп;<br>1 машина, 2 машина, 3 машина, 4 машина, 5 машина;<br>1 песи, 2 песи, 3 песи, 4 песи, 5 песи;<br>1 эт, 2 эт, 3 эт, 4 эт, 5 эт. | Һәрберсе 1 данә |
| 2.А3 форматында өй рәсеме. | Өй макеты | 1 данә |
| 3. А5 форматында таратма рәсемнәр. | «Минем гаилә»<br>Бабай, әби, әти, әни, малай, кыз. | Һәрберсе 15 данә |
| | «Ашамлыклар»<br>Ипи, алма, чәй, сөт. | Һәрберсе 15 данә |
| | «Уенчыклар»<br>Курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина. | Һәрберсе 15 данә |
| 4. Театр эшчәнлеге өчен атрибутлар. | Битлекләр: бабай, әби, әти, әни, малай, кыз, куян, аю, песи, эт. | Һәрберсе 15 данә |
| Бармак уеннары өчен атрибутлар | бабай, әби, әти, әни, малай, кыз, эт Акбай, песи Мияу, аю, куян. | Һәрберсе 15 данә |

**“Уйный-уйный үсәбез” проекты буенча 5-6 яшьлек балалар өчен**

| | | |
|---|---|---|
| 1. Күрсәтмә рәсемнәр. | «Минем гаилә»<br>Малай, кыз рәсемнәр («Курчакны киендер» уены. Кыз, малай өчен киемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), футболка, шорты, чалбар, сарафан - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 1 данә |
| | «Уенчыклар»<br>Зур уенчыклар: курчак, туп, машина - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә уенчыклар: курчак, туп, машина - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 1 данә |
| | «Ашамлыклар»<br>Аш, ботка, чәк-чәк, конфет, сок. | Һәрберсе 1 данә |
| | «Савыт-саба»<br>Зур рәсемнәр: кашык, тәлинкә, чынаяк - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә рәсемнәр: кашык, тәлинкә, чынаяк - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 1 данә |
| | «Җиләк-җимешләр»<br>Зур рәсемнәр: яшел алма, сары, кызыл, банан, апельсин, виноград, груша.<br>Кечкенә рәсемнәр: яшел алма, сары, кызыл, банан, апельсин, виноград, груша. | Һәрберсе 1 данә |

| | | |
|---|---|---|
| | «Яшелчәләр»<br>Зур рәсемнәр: кишер, бәрәңге, суган, кыяр, кәбестә.<br>Кечкенә рәсемнәр: кишер, бәрәңге, суган, кыяр, кәбестә. | Һәрберсе<br>1 данә |
| | «Киемнәр»<br>Зур рәсемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), чалбар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә рәсемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), чалбар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе<br>1 данә |
| | «Өй җиһазлары»<br>Зур рәсемнәр: карават, урындык, өстәл - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә рәсемнәр: карават, урындык, өстәл - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе<br>1 данә |
| | «Төсләр»<br>Палитра: зәңгәр, кызыл, сары, яшел. | Һәрберсе<br>1 данә |
| | «Саннар»10) | Һәрберсе<br>1 данә |
| 2. Таратма рәсемнәр. | «Минем гаилә»<br>Малай, кыз рәсемнәре: («Курчакны киендер» уены. Кыз, малай өчен киемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), футболка, шорты, чалбар, сарафан - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 15 данә |
| | «Уенчыклар»<br>Зур уенчыклар: курчак, туп, машина - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә уенчыклар: курчак, туп, машина - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 15 данә |
| | «Ашамлыклар»<br>Аш, ботка, чәк-чәк, конфет, сок. | Һәрберсе 15 данә |
| | «Савыт-саба»<br>Зур рәсемнәр: кашык, тәлинкә, чынаяк - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә рәсемнәр: кашык, тәлинкә, чынаяк - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 15 данә |
| | «Җиләк-җимешләр»<br>Зур рәсемнәр: яшел алма, сары, кызыл, банан, апельсин, виноград, груша.<br>Кечкенә рәсемнәр: яшел алма, сары, кызыл, банан, апельсин, виноград, груша. | Һәрберсе 15 данә |
| | «Яшелчәләр»<br>Зур рәсемнәр: кишер, бәрәңге, суган, кыяр, кәбестә.<br>Кечкенә рәсемнәр: кишер, бәрәңге, суган, кыяр, кәбестә. | Һәрберсе 15 данә |
| | «Киемнәр»<br>Зур рәсемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), чалбар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә рәсемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), чалбар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 15 данә |
| | «Өй җиһазлары»<br>Зур рәсемнәр: карават, урындык, өстәл - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә рәсемнәр: кровать, стул, стол - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 15 данә |
| 3.Буяу өчен график | 1 аю, 2 куян, 2 машина, 2 курчак, 3 бәрәңге, 4 кәбестә, 4 курчак, 5 песи, 6 алма, 6 кыяр, 7 туп, 7 бәрәңге, 8 кишер, | Һәрберсе 15 данә |

| | | |
|---|---|---|
| рәсемнәр | 9 суган, 10 эт. | |
| 4.Театр эшчәнлеге өчен атрибутлар. | Битлекләр: кишер, суган, кыяр, бәрәңге, кәбестә, алма. | Һәрберсе 15 данә |
| 5. Театр эшчәнлеге өчен атрибут лар. | 1.Өстәл театры өчен атрибутлар (конус формасында):<br>«Өч аю»: әти аю, әни аю, бала аю.<br>2. Өстәл театры өчен атрибутлар (конус формасында):<br>«Кем нәрсә ярата»: песи, эт, аю, куян, кәҗә, әтәч.<br>өстәл (зур, уртача зурлыкта, кечкенә);<br>урындык (зур, уртача зурлыкта, кечкенә);<br>карават (зур, уртача зурлыкта, кечкенә). | Һәрберсе 1 данә<br><br>Һәрберсе 1 данә |

**“Без инде хәзер зурлар-мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча**
**6-7 яшьлек балалар өчен**

| | | |
|---|---|---|
| 1.А 4 форматына күрсәтмә рәсемнәр. | Үрдәк, бүре, әтәч, тавык, зур тычкан, кечкенә тычкан, китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал, дәфтәр, кофе, пицца, бәрәңге фри, өчпочмак. | Һәрберсе 1 данә |
| | Шарлар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 1 данә |
| | Сюжетлы рәсемнәр: куян чана шуа, аю чана шуа, бүре чана шуа, төлке чана шуа, үрдәк чана шуа, тавык чана шуа, тычкан чана шуа, төлке бии, керпе йоклый, бүре йөгерә, төлке утыра, керпе уйный, аю йоклый, песи сөт эчә, эт ашый, төлке йөгерә, куян сикерә, тычкан ашый, әтәч җырлый, кыз кул юа, малай китап укый, кыз китап укый, төлке китап укый, куян китап укый, әни кул юа, әти йоклый, малай утыра, кыз бит юа, әби утыра, бабй йоклый. | Һәрберсе 1 данә |
| 2. А5 форматында таратма рәсемнәр. | Үрдәк, бүре, әтәч, тавык, зур тычкан, кечкенә тычкан, китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал, дәфтәр, кофе, пицца, бәрәңге фри, өчпочмак. | Һәрберсе 15 данә |
| | Шарлар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 15 данә |
| | Сюжетлы рәсемнәр: куян чана шуа, аю чана шуа, бүре чана шуа, төлке чана шуа, үрдәк чана шуа, тавык чана шуа, тычкан чана шуа, төлке бии, керпе йоклый, бүре йөгерә, төлке утыра, керпе уйный, аю йоклый, песи сөт эчә, эт ашый, төлке йөгерә, куян сикерә, тычкан ашый, әтәч җырлый, кыз кул юа, малай китап укый, кыз китап укый, төлке китап укый, куян китап укый, әни кул юа, әти йоклый, малай утыра, кыз бит юа, әби утыра, бабай йоклый. | Һәрберсе 15 данә |
| 8х10форматын да пиктограмма лар | Бии, йоклый, утыра, ашый, эчә, уйный, сикерә, йөгерә, укый, рәсем ясый, җырлый, чана шуа, мин, кыз, малай, әби, бабай. | Һәрберсе 15 данә |
| 15х20 форматында пиктограмма | Бии, йоклый, утыра, ашый, эчә, уйный, сикерә, йөгерә, укый, рәсем ясый, җырлый, чана шуа, мин, кыз, малай, әби, бабай, куян, төлке, песи, эт, аю, әтәч, тавык, үрдәк, | Һәрберсе 1 данә |

| | | |
|---|---|---|
| лар | керпе, тычкан. | |

**3.4. Көн тәртибе**

Көн тәртибе, белем бирү программасын тормышка ашыру шартларын, катнашучыларның белем бирү мөнәсәбәтләренә ихтыяҗларын, гамәлгә ашырыла торган вариатив белем бирү программаның үзенчәлекләрен, шул исәптән мәктәпкәчә яшьтәге балаларга өстәмә белем бирү программасын, санитар-эпидемиологик таләпләрне һәм башка үзенчәлекләрне исәпкә алып билгеләнгән. Көн тәртибе балаларның яшенә, аларның сәламәтлеге торышына, ихтыяҗларына һәм мәнфәгатьләренә туры килә. Режим һәм аның нигезендә төзелгән көн тәртибе - сыгылмалы һәм динамик. Көн режимының төп компонентлары озынлыгы санитар һәм гигиена нормалары һәм кагыйдәләре нигезендә саклана.

Татар теле шөгыльләре мәктәпкә әзерлек төркемендә бер тапкыр төркем белән үткәрелә, ике тапкыр режим моментында оештырыла. Мәктәпкә әзерлек төркемендә 30 минут алып барыла. Белем бирү эшчәнлеге зурлар төркемендәөч тапкыр, ә уртанчылар һәм кечкенәләр төркемендә атнага ике тапкыр режим моментларында оештырыла. Ул кабатлау, үткәннәрне ныгыту, төрле уеннар, яисә мультфильм карау рәвешендә узарга мөмкин. Темалар бер-берсенә бәйләнешле итеп, балаларның яшь үзенчәлекләрен искә алып сайланган. Белем бирү эшчәнлекләренең темасы катлауландырылып, кабатлана бара, алар баланың сөйләм телен камилләштерү максатын күздә тотып төзелгән. Һәр теманы йомгаклау өчен, гомумиләштерү эшчәнлеге буларак, анимацион күренешләр дә эшләнгән. Телгә өйрәтүнең төп формасы һәм чарасы булып белем бирү эшчәнлеге алына. Ул системалы рәвештә план буенча үткәрелә, Планга индивидуаль эш тә кертелә. Өйрәнелгән сүзләр, сүзтезмәләр, диалоглар эшчәнлектән тыш уен вакытларында активлаштырыла һәм ныгытыла, көндәлек аралашуда кулланыла. Яңа сүзләрне, сүзтезмәләрне, ситуацияләрне балалар аңламаган очракта, тәрбияче рус телендә сөйли. Пиктограммалар мәктәпкә әзерлек төркемендә, яңа сүзләр (фигыльләр) белән беренче тапкыр таныштырганда гына кулланыла. Балаларга темадан тыш артык сүзләр, уеннар, җырлар, шигырьләр төп программаны үзләштергән очракта бирелә. Бала татар телендә сүзне дөрес әйтмәгән очракта, тәрбияче баланы тыңлап сүзнең дөрес үрнәген бирә. Балалардан авазларның дөрес әйтелешен катгый таләп итмәскә кирәк. Тәрбияче сөйләмендә акцент, җирле диалект, аваз кимчелекләре булмаска тиеш. Тәрбияче сүзлек белән эшләгәндә татар һәм рус телләре өчен уртак сүзләргә таяна ала. Тәрбияче үзенең эшенә иҗади якын килергә, төрле алымнар, чаралар эзләп, аларны кулланырга тиеш. Укыту-методик комплекты кысаларында, лексик минимумны үзләштергән очракта, эшчәнлектә планлаштырылган уеннарның эчтәлеген үзгәртү, яңа алымнар кертү, баету хуплана. Төркемнәрдә балаларның һәм тәрбиячеләрнең татар телендә аралашулары һәрдаим булырга тиеш. Эшчәнлектә өйрәнелгән тел материалы, режим моментларында, уен эшчәнлеге аша (ситуатив күнегүләр,сюжетлы-рольле уеннар, үстерелешле диалоглар, сәхнәләштерү һ. б.) ныгытыла. Рус телле балаларны татарча сөйләшергә өйрәткәндә балалар бакчасы коллективы һәм эти-әниләрнең бердәм позициядә булуы уңай нәтиҗә бирә

**3.5.Бәйрәмнәр һәм күңел ачу чаралары**

Балалар бакчасында ел дәвамында төрле бәйрәмнәр, кичәләр, язучыларның туган көннәре, татар халкының милли бәйрәмнәре уздырыла. Болар “Сөмбелә, “Нәүрүз”, “Карга боткасы”, “Сабантуй”; Г.Тукай, М.Җәлил һәм башка язучыларның туган көннәре һ.б. бәйрәмнәр. Балаларда матурлыкны тоя, күрә белү сәләтен үстерүдә, туган якны ярату, халкыбызның гореф-гадәтләренә, йолаларына, милли бәйрәмнәренә ихтирам тәрбияләүдә халык педагогикасы чараларының йогынтысы зур.

**3.6. Норматив һәм норматив-методик документлар**

1. Конвенция о правах ребенка. Принята резолюцией 44/25 ГенеральнойАссамблеи от 20 ноября 1989 года─ ООН 1990.
2. Федеральный закон от 29 декабря 2012г. № 273-ФЗ (ред. от 31.12.2014, с изм. От

05.2015) «Об образовании в Российской Федерации» [Электронный ресурс] // Официальныйинтернет-портал правовой информации: ─ Режим доступа: pravo.gov.ru..
3. Федеральный закон 24 июля 1998 г. № 124-ФЗ «Об основных гарантиях прав ребенка в Российской Федерации».
4. Распоряжение Правительства Российской Федерации от 4 сентября 2014 г. № 1726-р о Концепции дополнительного образования детей.
5. Распоряжение Правительства Российской Федерации от 29 мая 2015 г. № 996-р о Стратегии развития воспитания до 2025 г.[Электронный ресурс].─ Режим доступа:http://government.ru/docs/18312/.
6. Постановление Главного государственного санитарного врача Российской Федерации от 19 декабря 2013 г. № 68 «Об утверждении СанПиН 2.4.1.3147-13 «Санитарно-эпидемиологические требования к дошкольным группам, размещенным в жилых помещениях жилищного фонда».
7. Постановление Главного государственного санитарного врача Российской Федерации от 15 мая 2013 г. № 26 «Об утверждении СанПиН 2.4.1.3049-13 «Санитарно-эпидемиологические требования к устройству, содержанию и организации режима работы дошкольных образовательных организаций» // Российская газета. – 2013. – 19.07(№ 157).
8. Постановление Главного государственного санитарного врача Российской Федерации от 3 июня 2003 г. № 118 (ред. от 03.09.2010) «О введении в действие санитарно-эпидемиологических правил и нормативов СанПиН 2.2.2/2.4.1340-03» (вместе с «СанПиН 2.2.2/2.4.1340-03. 2.2.2. Гигиена труда, технологические процессы, сырье, материалы, оборудование, рабочий инструмент. 2.4. Гигиена детей и подростков. Гигиенические требования к персональным электронно-вычислительным машинам и организации работы. Санитарно-эпидемиологические правила и нормативы», утв. Главным государственным санитарным врачом Российской Федерации 30 мая 2003 г.) (Зарегистрировано в Минюсте России 10 июня 2003 г., регистрационный № 4673)
9. Приказ Министерства образования и науки Российской Федерации от17 октября 2013г. № 1155 «Об утверждении федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования» (зарегистрирован Минюстом России 14 ноября 2013г., регистрационный № 30384).
10. Приказ Министерства образования и науки Российской Федерации от 6 октября 2009 г. № 373 (ред. от 29.12.2014) «Об утверждении и введении в действие федерального государственного образовательного стандарта начального общего образования» (зарегистрирован Минюстом России 22 декабря 2009 г., регистрационный № 15785).
11. Приказ Министерства образования и науки Российской Федерации от 17 декабря 2010 г. № 1897 (ред. от 29.12.2014) «Об утверждении федерального государственного образовательного стандарта основного общего образования» (зарегистрирован Минюстом России 1 февраля 2011 г., регистрационный № 19644).
12. Приказ Министерства образования и науки Российской Федерации от 17 мая 2012 г. № 413 (ред. от 29.12.2014) «Об утверждении федерального государственного образовательного стандарта среднего общего образования» (зарегистрирован Минюстом России 7 июня 2012 г.,регистрационный № 24480).
13. Приказ Минздравсоцразвития России от 26 августа 2010 г. № 761н (ред. от 31.05.2011) «Об утверждении Единого квалификационного справочника должностей руководителей, специалистов и служащих, раздел «Квалификационные характеристики должностей работников образования» (Зарегистрирован в Минюсте России 6 октября 2010 г. № 18638)
14. Письмо Минобрнауки России «Комментарии к ФГОС ДО» от 28 февраля 2014 г. № 08-249 // Вестник образования.– 2014. – Апрель. – № 7.
15. Письмо Минобрнауки России от 31 июля 2014 г. № 08-1002 «О направлении методических рекомендаций» (Методические рекомендации по реализации полномочий субъектов Российской Федерации по финансовому обеспечению реализации прав граждан на получение общедоступного и бесплатного дошкольного образования).

**Методик әсбаплар.**

1. Закирова К.В. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм эти-әниләрөчен хрестоматия.
2. Закирова К.В. На поляне детства: хрестоматия для воспитателей дошкольныхобразовательных учреждений и родителей.
5. Шаехова Р.К. Раз- словечко, два – словечко...: занимательное обучение татарскому языку.
6. Шаехова Р.К.Региональная программа дошкольного образования (Куаныч 2024г.)
7. Зарипова З.М. и др. Аудиокомплект к методическому пособию для детей 6-7лет “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар”. Шөгыль эшкәртмәләребуенча аудиоязмалар – 71 трэк.
9. Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибуллина И.Җ. “Туган телдә сөйләшәбез.Балалар бакчасында татар телендә тәрбия һәм белем бирү (беренче кече яшьтәгеләр төркеме): тәрбиячеләр өчен методик кулланма
10. Закирова К.В., Мортазина Л.М. Балачак – уйнап-көлеп үсәр чак: балалар бакчасында уеннар.
11. Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибуллина И.Җ. “Туган телдә сөйләшәбез.Балалар бакчасында татар телендә тәрбия һәм белем бирү (беренче кече яшьтәгеләр төркеме) методик кулланма өчен аудио-кушымта
12. Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибуллина И.Җ. “Туган телдә сөйләшәбез. Балалар бакчасында татар телендә тәрбия һәм белем бирү(икенче кече яшьтәгеләр төркеме) методик кулланма өчен аудио-кушымта.
13. Зарипова З.М., Кидрячева Р.Г., Шарипова Л.А.и др. Говорим по-татарски: рабочая тетрадь для детей 6-7 лет, изучающихтатарский язык с комплектом наклеек. Балаларга мөстәкыйль рәвештә, яисәтәрбиячеләр яки эти-әниләр белән эшләү өчен 20 бирем.
14. Тәмле сүз: әдәпле булу серләре : төз. Талия Шакирова. – Казан, 2013
15. Валиева Р.Т. Карга боткасы: Балалар бакчасы һәм мәктәп сәхнәсе өчен сценарийлар. Казан, 2015.
16. Төсләр: дидактик карточкалар( төз: С.И.Хәкимова) – Казан, 2018.
17. Хәрефләр: дидактик материаллар: карточкалар (төз.А.А.Галимова, Э.Ә.Хәбирова) – Казан, 2018.
18. Саннар: дидактик карточкалар (төз. Э.Киямова) – Казан, 2018.
19. Г.К.Мансурова “Уйный-уйный үсәбез: балалар өчен уеннар – Казан, 2014.
20. Э.Хуснутдинова. Гөмәр белән Гөлбикә- Казан, 2020.
21. Художественное-анимационное издание: Әкиятләр илендә - Казан, 2015.
22. Н.Яхина. “Кәккүкле алан” – балалр өчен җырлар.
23. Танцы народов Поволжья” аудиодиск – Казан, 2013
24. Аудио-китап “Татар әкиятләре” мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен.
25. З.Г.Ибраһимова. Шома бас: мәктәпкәчә яшьтәге балаларга татар бию хәрәкәтләре өйрәтү буенча аудио-кушымталы методик кулланма
26. Татар телендә мультфильмнар. № 1
27. Татар телендә мультфильмнар. № 2
28. Татар телендә мультфильмнар. № 3
29. Татар телендә мультфильмнар. № 4
30. Татар телендә мультфильмнар. № 5

**Аудио-җыентыклар**

- Музыкаль әкиятләр: “Сертотмас үрдәк”, “Бардым күлгә, салдым кармак”
- Музыкаль әкият: “Африка хикмәтләре” (Л. Батыр-Булгари музыкасы, Г. Каюмов пьесасы буенча).
- Балалар өчен җырлар һәм караоке “Бииләр итек-читекләр”(Л. Батыр-Булгари).
- Бакча балалары өчен биюләр “Шома бас”.
- Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен җырлы-биюле уеннар аудиоҗыентыгы һәм караоке “Җырлап-биеп уйныйбыз”:

1.Чәбәк-чәбәк итә ул (1-2 яшь);
2.Бир кулыңны, булсын матур түгәрәк (2-3 яшь);

3.Без шатлык таратабыз, уйнарга яратабыз (3-4 һәм 4-5 яшь);
4.Без-бәхетле, шат балалар, уйныйбыз әйлән-бәйлән (5-6 яшь);
5.Уйныйк бергә, биик бергә, ямь тулсын яшь күңелгә (6-7 яшь).

**3.7. Файдаланылган әдәбият:**


1. Шәехова Р.К. Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы, “Куаныч”, 2024.
2. Шәехова Р.К. Раз-словечко, два- словечко “Хэтер” 2011.
3.Зарипова З.М., Кидрячева Р.Г. Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү программасы. «Идел-Пресс», 2013.
4. Зарипова З.М., Кидрячева Р.Г. “Татарча сөйләшәбез”. 4-5 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, «Хәтер», 2011
5.Зарипова З.М., Кидрячева Р.Г. “Татарча сөйләшәбез”. 5-6 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, «Хәтер», 2012
6.Зарипова З.М., Кидрячева Р.Г. “Татарча сөйләшәбез”. 6-7 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, «Татарстан китап нәшрияты», 2012.
7.Ф.В. Хәзрәтова “Туган телдә сөйләшәбез”, 4-5 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү өчен методик ярдәмлек. Инновацион технологияләр үзәге. Казан, 2013
8. Зарипова З.М., Кидрячева Р.Г. “Туган телдә сөйләшәбез”. 5-7 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, «Хәтер», 2016.
9.Закирова К.В., Муртазина Л.Р. “Әй, уйныйбыз, уйныйбыз”.- Казан, 2013.
10.Зарипова З.М., Исаева Р.С. “Үстерешле уен”.- Казан, 2013.
11. К. В. Закирова, Л. Р. Мортазина, Балачак-уйнап,көлеп үсәр чак. -Казан. 2012 (балалар бакчасында уеннар)
12. К. В. Закирова, “Балачак аланы”. төзүчесе Казан. 2011.
13. “На поляне детства” автор-составитель К. В. Закирова, Казань 2011
14. Борһанова Р. А., Юсупов Ф. Ф. Балалар бакчасында татар теле өйрәтү программасы. Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган. – Казан: РИЦ «Школа», 2004.
15.М.А. Васильева, В.В. Гербова, Т.С. Комарова “Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы” Казан, “Мәгариф” нәшрияты. Москва, “Мозаика-Синтез”, 2006 ел.
16.Р.К.Шаехова “Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы” Казан, 2012 ел.
17. Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе Закирова К.В.;
18. Уйный-уйный үсәбез: балалар бакчасында уеннар: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма / К. В. Закирова. – Казан:Татар. кит.нәшр, 2010
19. Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. “Авазларны уйнатып” 1,2. Шаехова Р.К.;
20. Раз- словечко, два – словечко... Занимательное обучение татарскому языку Р.К. Шаехова;
21. З.М.Зарипова, А.Х.Габдрахимова, А.Т.Миникаева НОД в детском саду: методическое пособие для воспитателей детских садов. Балалар бакчасында бердәм белем бирү эшчәнлеге. – Казань, 2013.
22. Г.Ә.Нәбиуллина, Л.Г.Гыйләҗева Балалар дөньясы: мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен хрестоматия (зурлар төркеме). – Казан, 2016
23. Г.Ә.Нәсибуллина Татар телендә сөйләм үстерү (зурлар төркеме): мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен методик кулланма. – Казан, 2016.